# Изге Язмадан хикәяләр

## (Тәүрат, Зәбур, Инҗил китапларыннан)

Изге Китапны тәрҗемә итү институты
Мәскәү
2017

# Изге Язмадан хикәяләр

(Тәүрат, Зәбур, Инҗил китапларыннан)

Әлеге китапның текстын һәм аудио язмасын Изге Китапны тәрҗемә итү институтының сайтыннан (http://ibtrussia.org/en/media?id=TTR) табарга мөмкин

Рәсемнәр © Classic Bible Art LLC рөхсәте белән бирелә
ISBN 978-5-93943-235-1
© Изге Китапны тәрҗемә итү институты, 2017

# ДӨНЬЯНЫҢ ЯРАТЫЛЫШЫ

Иң әүвәл беркайда бернинди яктылык әсәре юк иде. Болытлар томалаган айсыз төндәге сыман дөм караңгылыкка чумган ул заманнарда әле күк йөзе дә, үсемлекләр дә, һичнинди тереклек иясе дә, шушы тоташ караңгылыкны үз күзләре белән күреп багардай адәм заты да юк иде. Әмма Аллаһы әйләнә-тирәнең мәңгегә мондый хәлдә калуын теләмәде һәм шуңа күрә якты дөньяны бар итте. Бер нәрсә дә үзеннән-үзе барлыкка килми: тирә-ягыбыздагы искиткеч матур һәм төзек-камил дөнья йөзе Бар итүченең бөеклеге һәм акылы-зирәклеге турында сөйли. Изге Китапта, Тәүратта, Аллаһының ни рәвешле Үз сүзе белән дөньяны яратуы хакында языла.

Аллаһы иң элек күкне һәм җирне бар итте.

Җир йөзе ул вакытта бик тә күрексез һәм буп-буш булып, котырынган сулар өстендә караңгылык хөкем сөрә иде; Аллаһының рухы-сулышы шул сулар өстендә гизеп йөри иде.

Аллаһы: «Яктылык булсын», – дип боерды, һәм яктылык булды.

Аллаһы яктылыкның яхшы булуын күрде һәм аны караңгылыктан аерды.

Аллаһы яктылыкны «көн» дип, ә караңгылыкны «төн» дип атады. Кич җитте, таң атты – беренче көн үтте.

Аллаһы: «Суларның уртасында бер гөмбәз* булсын һәм суларны бер-берсеннән аерсын», – дип боерды.

Һәм нәкъ шулай булды: Аллаһы гөмбәзне бар итте, гөмбәз астындагы суларны гөмбәз өстендәге сулардан аерды.

Аллаһы гөмбәзне «күк» дип атады. Кич җитте, таң атты – икенче көн үтте.

Аллаһы: «Күк астындагы сулар бер урынга җыелсын да, су астыннан туфраклы ялан калкып чыксын», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

Туфраклы яланны Аллаһы «җир» дип, җыелган суларны «диңгез» дип атады һәм моның яхшы булуын күрде.


Аллаһы: «Туфрактан яшеллекләр үсеп чыксын – орлык бирә торган үләннәр, җимешендә орлык өлгертә торган агачлар үссен», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

---

* *Гөмбәз – русчасы «купол».*

Җир өстендә яшеллекләр: орлык бирә торган үләннәр, җимешендә орлык өлгертә торган агачлар үсеп чыкты, һәм Аллаһы моның яхшы булуын күрде.
Кич җитте, таң атты – өченче көн үтте.

*ЯРАТЫЛЫШ 1:1–13*



## ДӨНЬЯНЫҢ ЯРАТЫЛЫШЫ
### *(дәвамы)*

Аллаһы: «Күк гөмбәзендә җир йөзен яктырта торган, көнне төннән аера торган яктырткычлар булсын, алар вакытны, ел фасылларын һәм көн исәбен күрсәтеп торсыннар», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы ике бөек күк җисемен: зурысы – көн белән, кечесе төн белән идарә итүче яктырткычларны һәм йолдызларны бар итте.

Җир йөзен яктыртып, көн вә төн белән идарә итсеннәр һәм яктылыкны караңгылыктан аерып торсыннар өчен Аллаһы аларны күк гөмбәзенә урнаштырды һәм моның яхшы булуын күрде.

Кич җитте, таң атты – дүртенче көн үтте.

Аллаһы: «Сулар терек җан ияләре белән тулсын һәм күк белән җир арасында кошлар очып йөрсен», – дип боерды.

Аллаһы төрледән-төрле балыкларны, суда яшәүче җан ияләрен вә кошларны бар итте һәм моның яхшы булуын күрде.

Аллаһы: «Үрчегез, ишәегез, диңгез суларын тутырыгыз, җир йөзендә кош-корт үрчегәннән-үрчесен», – дип һәммәсенә Үзенең фатихасын бирде.

Кич җитте, таң атты – бишенче көн үтте.

Аллаһы: «Җир йөзе үзендә төрле токымдагы җан ияләрен: мал-туарны, җәнлекләрне һәм кыргый җанварларны булдырсын», – дип боерды, һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы төрле токымдагы кыргый җанварларны, мал-туарны вә барча җәнлекләрне бар итте һәм моның яхшы булуын күрде.

Чиксез кодрәткә ия булган Бар итүченең сүзе белән яратылган һәм рәхәт-талгын тынлыкка чумган җир йөзе искиткеч гүзәл иде. Әмма яратылыш әле тәмамланмаган иде. Шушы матур дөньяда яшәп, үзенең Бар итүчесе белән аралашып көн күрер өчен, Аллаһы җирдә кешене яратырга карар кылды.

*ЯРАТЫЛЫШ 1:14–25*



## БЕРЕНЧЕ КЕШЕЛӘРНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Аллаһы: «Кешене Үз сыйфатыбызда, Үзебезгә охшатып яратыйк. Кеше диңгездәге балыклар, күктәге кошлар, барча мал-туар, бөтен җир йөзе һәм җирдә хәрәкәт итүче һәммә тереклек иясе өстеннән хакимлек итсен», – диде.

Шулай итеп, кешене Аллаһы Үз сыйфатында, Үзенә охшатып, ир-ат һәм хатын-кыз итеп яратты.

Аларга Үзенең фатихасын биреп: «Үрчегез һәм ишәегез, җир йөзен тутырыгыз, аны буйсындырыгыз; диңгездәге балыкларга, күктәге кошларга, җир йөзендә хәрәкәт иткән барлык җан ияләренә хуҗа булыгыз», – диде. Аллаһы әйтте: «Җир өстендә үскән, орлык өлгертә торган барча үләнне, барча агачларның җимешләрен сезгә тапшырам – алар сезгә ризык булсын; җир йөзендәге һәрбер җанварга, күктәге һәрбер кошка, үзендә тереклек сулышын тойган һәрбер җан иясенә азык итеп яшел үлән насыйп итәм». Һәм нәкъ шулай булды.

Аллаһы Үзе яраткан нәрсәләрне күздән кичерде һәм бар нәрсәнең яхшы булуын күрде. Кич җитте, таң атты – алтынчы көн үтте.

Күкнең һәм җирнең, андагы бөтен нәрсәнең яратылышы әнә шулай тәмамланды. Җиденче көнгә Аллаһы Үз эшен төгәлләде һәм, бөтен эшләрен бетереп, ул көнне ял итте.

Аллаһы кешеләрне матур һәм бәхетле итеп яратты. Алар үзләренең Бар итүчесенә һәм бер-берсенә мәхәббәтле мөнәсәбәттә булдылар. Ир кешенең исеме – Адәм, хатын-кызныкы – Һава иде.

Аллаһы, Үзе бар кылган җирне кайгыртсыннар өчен, аны кешеләр кулына тапшырды. Адәм белән Һавага Үзенең фатихасын биреп, Аллаһы көн чыгышы тарафында, Гадәндә, оҗмах бакчасы булдырды һәм аларны шунда урнаштырды. Аллаһы аларга бакчаны саклау һәм эшкәртү вазифасын йөкләде.

*ЯРАТЫЛЫШ 1:26–31; 2:7–22*



## АДӘМ БЕЛӘН ҺАВАНЫҢ ОҖМАХТАН КУЫЛУЫ

Ләкин Адәм белән Һава Аллаһы сүзеннән чыктылар, һәм Ул аларны оҗмахтан куып җибәрде. Бу хәл болай булды.

Яхшылыкны һәм яманлыкны таныта торган белем агачыннан башка Раббы аларга бакчадагы һәммә агачның җимешен ашарга рөхсәт итте. «Әгәр шушы әмеремне бозсагыз, үләчәксез», – дип кисәтеп куйды Ул аларны.

Әмма Иблис – Раббыга каршылык күрсәтүче зат – Адәм белән Һаваны харап итәргә ниятләде һәм, елан кыяфәтенә кереп, Һава янына килде дә: «Аллаһы сезгә чыннан да, бакчадагы һичбер агачтан җимеш ашамагыз, дидеме?» – дип сорады. «Бакчада үскән һәммә агачның җимешен ашарга ярый безгә, – дип җавап бирде хатын. – Әмма Аллаһы әйтте, бакча уртасындагы агачның җимешен ашамагыз, аңа хәтта кагылмагыз да, юкса үләрсез, диде». Елан исә аңа: «Юк, үлмисез, – диде, – чөнки Аллаһы белә: әлеге агачның җимешен ашаган көнне сезнең күзләрегез ачылыр, һәм сез яхшылык белән яманлыкның нәрсә икәнен белә торган илаһлар кебек булырсыз».

Агачтагы җимешләрнең карап торышка гүзәл, ашар өчен яраклы булуын күреп һәм аларның белем бирү хасиятенә кызыгып, Һава агачтан җимеш өзеп ашады, иренә дә өзеп бирде, ул да ашады. Шуннан Аллаһы Адәмгә болай диде: «Хатыныңның сүзен тыңлаган һәм Мин „ашама“ дип кисәткән агачның җимешен ашаган өчен җир туфрагына Минем ләгънәтем төште; син гомерең буе тамагыңа ризыкны җәфа чигеп табарсың. Яратылмыш туфрагыңа кире әйләнеп кайтканчыга кадәр ашар икмәгеңне син маңгай тире түгеп табарсың; чөнки син үзең – туфрак, туфрактан яратылдың һәм янә туфракка әвереләчәксең». Шул рәвешле, Аллаһы Адәм белән Һаваны оҗмах бакчасыннан куды, һәм алар инде башкача анда әйләнеп кайта алмады.

Беренче кешеләрнең гөнаһ эш кылып бозыклыкка бирелүе әнә шулай булды.

*ЯРАТЫЛЫШ 3:1–23*



## ТУФАН.* НУХ ПӘЙГАМБӘР КӨЙМӘСЕ

Ничәмә-ничә гасырлар узды. Адәм белән Һавадан туа килгән кешеләр җир йөзендә үрчегәннән-үрчи бирде. Баштагы мәлләрдә аларның күбесе, Аллаһыдан куркып, хак юлдан йөрде, әмма тора-бара адәм балалары Аллаһы ихтыярына буйсынмый башлады. Бары тик Нух исемле кеше генә, Раббысына тугрылык саклап, Аның ихтыярына буйсынып яшәде. Нухның йөрәгендә Аллаһы Рухы бар иде.

Раббы күрде: җир йөзендә яшәүче адәм балаларын азгынлык басты, кешенең бөтен күңеле һәм уй-фикере һәрвакыт явызлыкта булды, хак юлдан йөрүче һичкем калмады. Шуннан Аллаһы әйтте: «Җир йөзендә яшәүче адәмнәрнең һәммәсен юк итәчәкмен, чөнки Мин аларны бар итүемә үкенәм», – диде.

Раббы карашына фәкать Нух кына мәрхәмәткә лаек күренде. Аллаһы Нухка болай диде: «Бөтен кешелек дөньясын юк итәм, чөнки кешеләр аркасында җир йөзе явызлык белән тулды. Гофәр агачыннан** үзеңә көймә ясап, аның эчендә бүлмәләр кор, көймәнең эчен-тышын сумалала. Шуннан соң Мин, җир йөзендә яшәүче барлык җан ияләрен кырып бетерер өчен, җир йөзен туфан суларына батырам. Әмма синең белән Мин килешү төзим, һәм син улларың, хатының, киленнәрең белән бергә көймәгә кереп урнашырсың».

*ЯРАТЫЛЫШ 6:5–18*

---

* *Туфан – су ташкыны*

** *Гофәр агачы – кипарис сыман, сумалалы һәм ылыслы агач.*



## ТУФАН

Аллаһының барлык боерыкларын Нух җиренә җиткереп үтәде. Көймә әзер булгач, Аллаһы аңа: «Бөтен гаиләң белән көймәгә кер, – диде, – чөнки кешеләр арасында бары син генә Миңа тугры булдың. Җир йөзендә токымнары сакланып калсын өчен, чиста хайваннардан ата һәм ана җенестәге җиде парны, чиста булмаганнардан* шулай ук ата һәм ана җенестәге берәр парны, бар төр кошлардан җиде парны үз яныңа ал. Чөнки җиде көннән Мин җир йөзенә кырык көн һәм кырык төн буе тоташтан яңгыр яудырачакмын – Үзем бар иткән бөтен нәрсәне юк итәчәкмен».

Нух һәммәсен дә Аллаһы кушканча эшләде: хатыны, уллары һәм киленнәре белән бергә көймәгә керде, чиста хайваннардан җидешәр пар һәм чиста булмаганнардан берәр пар җан иясен үзе белән көймәгә алды. Һәммәсе көймәгә урнашып беткәч, Аллаһы Үзе алар артыннан ишекне япты. Җиде көннән соң туфан купты – җир йөзен томалап яңгыр коя башлады; ул кырык көн һәм кырык төн тоташтан яуды. Су ташкыны артканнан-арта барды, тора-бара бөтен җирне каплап алды, һәм көймә су өстеннән йөзеп китте. Су шулкадәр артты ки, хәтта иң биек тау түбәләре дә су астында калды, сулышы булган бөтен җан иясе: кешеләр дә, терлекләр дә, барлык җәнлекләр һәм кошлар да һәлак булды – җир йөзендәге тереклек юкка чыкты. Фәкать Нух һәм аның белән бергә көймәдә булганнар гына исән калды.

*ЯРАТЫЛЫШ 7:1–23*

* *Чиста һәм чиста булмаган хайваннар – яһүдләр өчен ашарга яраклы һәм яраксыз хайваннар.*



## ТУФАН СУЛАРЫНЫҢ КАЙТУЫ

Су күтәрелү йөз илле көн дәвам итте. Аллаһы, Нухны һәм аның белән бергә көймәдә булган барлык хайваннарны исенә төшереп, җир өстенә җил истерде. Коеп яуган яңгыр туктап, сулар әкренләп кими башлады. Көннәрдән беркөнне Нухның көймәсе Арарат тавының түбәсенә килеп утырды. Кырык көн үткәч, җир өстеннән су китеп беткәнме-юкмы икәнен белер өчен, Нух көймәнең тәрәзәсен ачып бер козгынны тышка очырды. Җир өсте сулардан арынганчыга кадәр козгын шулай әле очып китеп, әле кабат кайтып йөрде. Аннары Нух бер күгәрченне очырды, әмма күгәрчен аның янына көймәгә әйләнеп кайтты, чөнки җир өстеннән су китеп бетмәгән иде әле. Җиде көн узгач Нух янә күгәрченне тышка очырды. Кичен күгәрчен томшыгына яшь зәйтүн ботагы эләктереп кире кайтты. Шул рәвешле Нух җир өстендәге суларның кимүен белде.

Яңадан да җиде көн үткәннән соң, Нух күгәрченне тагын очырды, тик бу юлы инде күгәрчен әйләнеп кайтмады. Шуннан Нух көймәнең түбәсен ачып карады һәм җирнең коры икәнлеген күрде. Аллаһы Нухка: «Хатының, улларың һәм киленнәрең белән көймәдән чык, көймәдәге барлык хайваннарны да үзең белән алып чык; алар җир йөзенә таралсыннар, үрчеп-ишәеп җир өстен тутырсыннар», – диде.

*ЯРАТЫЛЫШ 7:24 – 8:17*



## САЛАВАТ КҮПЕРЕ ҺӘМ АЛЛАҺЫНЫҢ КЕШЕ БЕЛӘН КИЛЕШҮ ТӨЗҮЕ

Нух үзенең гаиләсе белән көймәдән чыкты һәм барлык төр җан ияләрен дә, кошларны да чыгарды. Җан ияләре җир йөзе буйлап таралышты, кошлар төрлесе төрле якка очып китте.

Нух таштан мәзбәх, ягъни корбан малын яндыру өчен махсус корылма ясады да чиста саналган һәр төр хайван вә кошлар арасыннан берничәсен сайлап алып Раббыга корбан китерде. Нухның корбан китерүен Аллаһы хуш күрде, һәм Ул: «Кешеләр аркасында җир йөзенә кабат каргышым төшмәс, – дип хәл кылды. – Кеше күңелендәге явызлыклар балачактан ук килсә дә, тереклек дөньясын кабат үлемгә дучар итмәм. Дөньяның киләчәк яшәешендә чәчү һәм уру да, суык һәм эссе дә, җәй һәм кыш та, көн һәм төн дә булып торыр».

Нухка һәм аның улларына Үзенең фатихасын биреп Аллаһы әйтте: «Мин сезнең белән һәм сездән соң туачак нәсел-нәсәбегез, шулай ук сезнең белән көймәдән чыккан барлык җан ияләре белән килешү төзим: моннан ары җирдәге терек затлар туфан суларында һәлак булмаячак, җир йөзен суга батырган туфан бүтән кабатланмаячак. Минем белән җирдәге җан ияләре арасында төзелгән килешүемнең билгесе итеп Мин болыттан җиргә таба салават күпере сузам. Җир йөзенә яңгыр болыты җибәреп, болыттан салават күпере сузылуга, Минем белән терек җан ияләре арасындагы килешүне искә төшерермен. Җир йөзендә яшәүче җан ияләре белән төзегән килешүемнең билгесе әнә шул салават күпере булыр».

*ЯРАТЫЛЫШ 8:18–22; 9:8–17*



## ИБРАҺИМ ПӘЙГАМБӘР

Нухның тагын да балалары туды, һәм алардан күп санлы халыклар барлыкка килде. Нухның нәсел варисларыннан берсе Ибрам исемле булып, соңрак Аллаһы аңа «бик күп халыкларның атасы» дигән мәгънәне аңлатучы «Ибраһим» дигән исем куша. Ибраһим, бар өметен Аллаһыга баглап, Аңа тугрылык саклый һәм Аның сүзеннән чыкмый торган бер бәндә иде. Аллаһы аны Үзенең дусты дип атый. Инҗилдәге «Яхъя бәян иткән яхшы хәбәр» (15:14) исемле китапта Аллаһы безгә дә: «Минем әмерләремне үтәсәгез, минем дусларым булырсыз», – дип әйтә.

Бервакыт Аллаһы Ибраһимга болай диде: «Яшәгән җиреңне, туганнарыңны, атаң йортын калдыр да Мин күрсәткән җиргә күченеп кит. Мин синнән бөек бер халык тудырырмын һәм сиңа Үземнең фатихамны бирермен, исемеңне шөһрәтле итәрмен; һәм син фатиха-бәрәкәт иясе булырсың. Сиңа игелек теләгәннәргә Мин игелек кылырмын, сине каһәрләгәннәргә ләгънәтемне яудырырмын. Җир йөзендәге халыкларның һәммәсе синең аша Минем фатихамны алыр».

Ибраһим Аллаһы боерганча эшләде: үзе белән хатыны Сараяны, бертуган энесенең улы Лутны, туплаган бар мөлкәтен, кул астындагы барлык хезмәтчеләрен алды да Аллаһы күрсәткән тарафка – Кәнган җиренә юнәлде.

Кәнган җиренә килеп җитеп Мөре имәнлеге дигән урынга туктауга, Ибраһимның каршысында Аллаһы пәйда булды һәм: «Менә бу җирләрне Мин синең токымыңа бирәм», – диде.

*ЯРАТЫЛЫШ 12:1–7*



## АЛЛАҺЫНЫҢ ИБРАҺИМГА БИРГӘН ВӘГЪДӘСЕ

Аллаһы Ибраһимга әйтте: «Әйләнә-тирәңә күз сал – карашыңны көн ягына, төн ягына, көн чыгышы һәм көн батышы тарафына юнәлт, – диде. – Карашың җиткән бу җирләрнең һәммәсен Мин сиңа һәм синең токымыңа мәңгегә бирәм. Синең нәсел-нәсәбеңне Мин ком бөртекләре санынча ишле итәрмен; кем дә булса туфрактагы ком бөртекләрен санап бетерә алса, шул кеше генә синең нәсел варисларыңның санын белә алыр».


Ибраһим Мәмре имәнлеге дигән җиргә килеп төпләнде һәм шунда Аллаһы хөрмәтенә мәзбәх корды.

Күпмедер вакыттан соң Ибраһим янына Аллаһы иңеп болай диде: «Мин – синең калканыңдыр; аласы бүләгең синең зур булыр». Ибраһим исә, Аллаһыга җавап итеп: «И Хуҗам, и Раббым, Син миңа нәрсә бирмәкчесең? – диде. – Бала атасы була алмадым инде. Син миңа бала насыйп итмәдең, шуңа күрә өемдәге бер хезмәтчем минем мирасчым булыр». Аның бу сүзләренә каршы Раббы: «Синең мирасчың ул түгел, ә бәлки синнән туган үз балаң булыр», – дип җавап бирде. Аннары Ул Ибраһимны чатырыннан һавага алып чыкты һәм: «Башыңны күтәреп күк йөзенә кара да, булдыра алсаң, андагы йолдызларны санап чык, – диде. – Синең нәсел варисларың әнә шул йолдызлар санынча булыр».

Ибраһим Аллаһыга ышанды, һәм Аллаһы моны Ибраһимның тугрылыгы итеп кабул итте.

Аллаһы Ибраһимга әйтте: «Хатыныңа бүтән Сарая дип дәшмә. Моннан ары аңа „байбикә, ханым“ дигәнне аңлатучы Сара исемен кушам. Мин аны фатихалыйм, һәм аңардан синең бер улың туар; хатының күп халык-кавемнәрнең анасы булыр, аның нәселеннән патшалар чыгар».

*ЯРАТЫЛЫШ 13:14–16; 15:1–6; 17:15–16*



## ИБРАҺИМНЫҢ ИСХАКНЫ КОРБАН ИТӘРГӘ ҖЫЕНУЫ

Аллаһы вәгъдә иткәнчә, Сараның улы туды. Ибраһим аңа Исхак дип исем кушты.

Исхак үсә төшкәч, Раббы Ибраһимның иманын һәм тугрылыгын сынап карарга булды, аңа: «Бердәнбер сөекле улың Исхакны ал да Мориа җиренә юл тот. Мин күрсәткән тауга барып җиткәч, корбанлык учагы өстендә улыңны корбанга китер», – диде.

Аллаһы кушканны эшләү Ибраһим өчен гаять авыр эш иде, тик ул каршы сүз әйтмәде. Таңнан торып корбанлык учагы өчен утын әзерләде, аны ишәгенә төяп, ике хезмәтчесе белән улы Исхакны ияртте дә Раббы күрсәткән җиргә карап юлга чыкты.

Атасының нинди малны корбан итәргә җыенганын белмәгән Исхак: «Әти! Менә утыныбыз да, ут та бар, ә корбанлык бәрәне кайда соң?» – дип сорады. «Корбанлык бәрәнен Аллаһы Үзе боерыр, улым», – дип җавап бирде Ибраһим.

Аллаһы күрсәткән урынга килеп җиткәч, Ибраһим үзенең хезмәтчеләрен тау итәгендә калдырды һәм, Исхак белән югары күтәрелеп, ташлардан мәзбәх корды, аннары шул урынга утынны тезеп өйде дә кул-аяклары бәйләнгән Исхакны утын өеме өстенә яткырды. Әмма шулчак күкләрдән Раббы фәрештәсе өн салып: «Ибраһим! Ибраһим! – дип эндәште. – Улыңа кул күтәрмә, берни дә эшләмә аңа. Инде Мин беләм: син Аллаһыдан куркасың, Аны хөрмәт итәсең һәм Аның хакына үзеңнең бердәнбер улыңны корбан итәргә әзер икән. Аллаһы сиңа Үзенең фатихасын бирер – нәселеңне күктәге йолдызлар, диңгез ярындагы ком бөртекләре санынча ишәйтер. Аллаһы сүзенә колак салган өчен, җир йөзендәге халыкларның һәммәсе синең токымың аша фатихалы булыр», – диде.

*ЯРАТЫЛЫШ 22:1–18*



## ЙОСЫФ – ЯГЪКУБНЫҢ ЯРАТКАН УЛЫ

Күпмедер вакытлар үткәч, Исхакның улы туа, аңа Ягъкуб дип исем кушалар. Соңрак Аллаһы аңа Исраил дигән исем бирә. Ягъкубның Рубин, Шимун, Леви, Яһүд, Дан, Нәптали, Гәд, Әшир, Исәсхәр, Зәбулун, Йосыф, Беньямин исемле унөч улы һәм Динә исемле бер кызы була. Ягъкуб Йосыфны бүтән балаларыннан артыграк ярата, чөнки Йосыф аның картлык көнендә туган баласы иде.

Унҗиде яшенә җиткәч, Йосыф үзенең агалары белән бергә сарыклар көтә башлады. Агалары кылган кырын эшләрне ул атасына кайтып сөйли торган булды. Бервакыт Ягъкуб Йосыфка төсле тукымадан тегелгән затлы кием бүләк итте. Аталарының Йосыфны ныграк яратуын күргән агалары энеләренә нәфрәт белән карый башладылар.

*ЯРАТЫЛЫШ 37:1–4*



## ЙОСЫФНЫҢ ТӨШЛӘРЕ

Бервакыт Йосыф төш күрде һәм аны агаларына сөйләде. «Тыңлагыз әле, мин сезгә күргән төшемне сөйлим, – диде ул. – Имеш, без барыбыз да кырда көлтә бәйлибез икән. Шулчак мин бәйләгән көлтә җир өстендә туп-туры утырып калды, ә сез бәйләгән көлтәләр, минем көлтәне уратып алып, аның алдында баш иделәр».

Агалары аңа: «Син безнең өстән хаким булмакчымы, безне үзеңә буйсындырмакчымы?» – дип ризасызлык белдерделәр һәм аны тагын да ныграк күрәлмас булдылар.

Йосыф тагын бер төш күрде, аны да агаларына сөйләде: «Менә, мин тагын бер төш күрдем, – диде. – Имеш, кояш та, ай да, унбер йолдыз да миңа баш иделәр».

Төшен агаларына гына түгел, атасына да сөйләгәч, атасы ачуланып әйтте: «Нәрсә аңлата синең бу төшең? Мин, анаң, агаларың синең каршыңа килеп җиргә кадәр баш иярга тиешме?»

Агаларының Йосыфка ачуы чыкты, аталары исә әлеге сүзләрне күңеленә салып куйды.

Бервакыт Йосыфның агалары ерак кырларда көтү көтә иде, һәм Ягъкуб: «Агаларың исән-имин генә йөриме икән, белеп кайт», – дип Йосыфны алар янына җибәрде. Йосыф юлга кузгалды.

Агаларын эзләп тапканчы, кырда ул озак йөрде. Агалары исә, Йосыфның якынлашып килүен ерактан ук күреп алып, аны үтерү турында үзара киңәш-табыш итә башладылар. «Әнә төш хастасы килә, – диеште алар усалланып. – Үтерик тә мәетен берәр чокырга ташлыйк. Ерткыч хайван ашады, дип әйтербез. Шуннан карарбыз, күргән төшләре рас килерме икән!»

*ЯРАТЫЛЫШ 37:5–20*



## АГАЛАРЫНЫҢ ЙОСЫФНЫ КОЛЛЫККА САТУЫ

Агалары арасыннан иң өлкәне, Рубин исемлесе, кардәшләренең кара ниятен ишетеп, Йосыфны алар кулыннан коткарып калырга һәм аны исән-имин хәлдә атасы янына кайтарып җибәрергә уйлады. Шуңа күрә кардәшләрен Йосыфны үтермәскә, чүлдәге берәр чокырга ташлап калдырырга үгетли башлады. Тегеләр Рубинның сүзенә күнделәр һәм, яннарына Йосыф килеп җитүгә, аның өстендәге төсле затлы киемнәрне салдырып алып, үзен тирән бер чокырга төртеп төшерделәр.

Шулчак алар товар төяп Мисырга баручы сәүдәгәрләр кәрванын күреп алдылар. Агаларының берсе, Яһүд дигәне, Йосыфны сәүдәгәрләргә сатып җибәрергә тәкъдим итте. Барысы да аның белән ризалашты һәм, кәрванчылар алар янына якынлашкач, Йосыфны коедан чыгарып сәүдәгәрләргә сатып җибәрделәр.

Сәүдәгәрләр Йосыфны Мисырга алып киттеләр, агалары исә көтүдәге бер кәҗә бәтиен тотып суйдылар да, шуның канына Йосыфның киемнәрен манчып, аталарына китерделәр: «Без менә нәрсә таптык, – диде алар. – Кара әле, синең улыңның киеме түгелме соң бу?» Ягъкуб, киемне танып: «Әйе, улым Йосыфның киеме бу, – диде. – Йосыфымны ерткыч җанвар ботарлаган!» Улларының ялган сүзләренә ышанып, яраткан улы Йосыф өчен Ягъкуб озак көннәр күз яшьләре түкте.

*ЯРАТЫЛЫШ 37:21–35*



## ЙОСЫФ – САРАЙ ХЕЗМӘТЧЕСЕНЕҢ ЙОРТЫНДА ИДАРӘЧЕ

Мисыр иленә килеп җиткәннән соң, сәүдәгәрләр Йосыфны Мисыр фиргавененең сарай хезмәтчесенә – җансакчылар башлыгы Потифарга коллыкка саттылар. Аллаһы беркайчан да Йосыфны Үзенең ярдәменнән ташламады. Шуңа күрә хәтта коллыкта да Йосыфның һәр эше уң булды.

Йосыф алынган һәр эшнең Раббы ярдәме белән көйле баруын хуҗасы Потифар да сизеп алды һәм, Йосыфны үз йортының идарәчесе итеп билгеләп, бар булган мал-мөлкәтен аның карамагына тапшырды. Йосыф хакына дип Аллаһы сарай хезмәтчесенең йортына Үзенең фатихасын күндерде. Фиргавен хезмәтчесенең йорт-җирендә Йосыф зирәклек белән идарә итте, шул сәбәпле хуҗасы һичнинди борчу-мәшәкать белмәде.

Күркәм йөзле, мәһабәт буй-сынлы Йосыфка Потифар хатынының гыйшкы төшеп, Йосыфны ул зина кылырга күндермәкче булды. Әмма хуҗасының хатынына Йосыф: «Хуҗам бар булган мөлкәтен ышанып миңа тапшырды, һәм мин нишләсәм дә ирекле мен, ләкин сиңа кагыла алмыйм, чөнки син – аның хатыны. Ничек итеп мин Аллаһы каршында шундый зур гөнаһ кыла алыйм?!» – дип аның гыйшкын кире какты.

Читкә тибәрелгән хатын Йосыфтан үч алырга ниятләде һәм иренә: «Йортыбызга син алып кайткан теге кол мыскыл итмәкче булып яныма керде. Әмма мин тавыш куптаргач, кулымда киемен калдырып чыгып качты», – дип егеткә нахак бәла якты. Бу сүзләрне ишетеп, Потифарның бик нык ачуы чыкты, һәм ул Йосыфны патша тоткыннарын яба торган төрмәгә ташлады.

*ЯРАТЫЛЫШ 39:1–20*



## ЙОСЫФ ТӨРМӘДӘ

Әмма Йосыф төрмәдә чакта да Раббысы аның янында булды, ярдәменнән ташламады. Төрмә башлыгы күңелендә Аллаһы Йосыфка карата мәрхәмәтле караш уятып, әлеге башлык Йосыфны барлык тоткыннар өстеннән карап торучы итеп куйды. Бөтен эшләрен тулысынча Йосыфка ышанып тапшырган төрмә башлыгы үзе һичнәрсә өчен борчылмады. Раббы исә, Йосыф янында булып, аның һәр эшен уңышлы кыла иде.

Йосыф яткан әлеге төрмәгә фиргавеннең ике хезмәтчесен дә япкан иделәр. Элек аларның берсе мәҗлесләрдә фиргавен касәсенә шәраб коючы, икенчесе фиргавен табынына ризык китерүче икмәкче хезмәтен башкарган. Мисыр патшасы алдында гаепләре чыгып, аларның икесен дә төрмәгә япканнар.

Бервакыт шәрабчы белән икмәкченең һәр икесенә төш керде, ләкин алар аны ничек дип тә юрарга белмәде. «Төш юрау Аллаһы иркендә түгелме?! – диде аларга Йосыф. – Күргән төшегезне сөйләгез әле». Беренче булып үзенең төшен шәрабчы сөйләде. Ул бер йөзем агачы күргән, аның өч ботагы бар икән. Шуннан агачта чәчәкләр күренгән, тиздән җимешләре дә өлгереп җиткән. Шәрабчы, әлеге җимешләрне җыеп алып, фиргавен касәсенә сыккан да аңа биргән.

Йосыф шундук шәрабчының төшен юрап бирде: «Өч ботак – өч көн дигән сүз. Өч көннән фиргавен сине элекке урыныңа кире кайтарыр, һәм син, яңадан шәрабчы вазифасын башкарып, аңа касәсен биреп торырсың. Шул чагында син, мине исеңә төшереп, бу йорттан чыгарырга булыш».

Аннары икмәкче дә үзенең төшен сөйләп бирде. Аның баш түбәсенә өсте-өстенә өч кәрзин куелган, имеш. Иң өстәге кәрзин фиргавен өчен төрле ризыклар белән тулган, әнә шул ризыкларны кошлар чукып-чукып китә икән.

Икмәкченең төшен тыңлаганнан соң, Йосыф әйтте: «Өч кәрзин – өч көн дигән сүз. Өч көннән сине фиргавен чакырып алыр да агачка асып куярга боерыр, һәм кошлар килеп синең тәнеңне чукыр».

Раббысы Йосыфка белдергәнчә, өч көн үтүгә һәммәсе дә нәкъ шулай булды. Әмма баш шәрабчы инде Йосыфның гозерен оныткан иде.

*ЯРАТЫЛЫШ 39:21–23; 40:1–22*



## ЙОСЫФНЫҢ ФИРГАВЕН КҮРГӘН ТӨШЛӘРНЕ ЮРАВЫ

Ничектер шулай фиргавен бер төш күрде. Ул, имеш, елга ярында басып тора икән. Шулчак елга суыннан көр-симез җиде сыер килеп чыга да яр буе камышлыгында утлап йөри башлый. Аннары судан җиде арык сыер килеп чыга һәм теге көр-симез сыерларны ашап бетерә. Шуннан фиргавен йокысыннан уянды. Аннан ул тагын йоклап китте һәм бу юлы икенче бер төш күрде. Имеш, бер сабактан яхшы, тук орлыклы җиде башак үсеп чыккан икән. Алар янында ук ач орлыклы, җилләрдән куырылып беткән янә җиде башак үсеп чыккан да теге тук-симез орлыклы җиде башакны ашап бетергән.

Йокысыннан уянуга, фиргавеннең күңеленә шик керде. Мисырның барлык акыл ияләрен чакыртып, ул аларга үзенең төшләрен сөйләп бирде, ләкин аларның мәгънәсен юрардай кеше табылмады.

Шулчак баш шәрабчы үзе белән бергә төрмәдә утырган Йосыф исемле егетнең аңа һәм икмәкчегә төш юрап бирүен һәм юраганнарының дөрескә чыгуын фиргавенгә сөйләп бирде. Фиргавен шундук Йосыфны чакыртып алып: «Син төш юрый беләсең дип ишеттем», – диде. Йосыф исә, фиргавенгә җавап итеп: «Бу минем кодрәтемдә түгел. Фиргавенгә хәерле җавапны Аллаһы Үзе ирештерер», – диде. Фиргавен аңа төшләрнең һәр икесен сөйләп бирде, һәм Йосыф аңа болай дип җаваплады: «Аллаһы алда кыласы эшенең хәбәрен фиргавенгә ирештерә. Җиде симез сыер һәм җиде тук башак ул – Мисыр җирендә җиде ел дәвамында бөек муллык чоры булачак дигән сүз. Ә инде җиде арык сыер һәм ач орлыклы җиде башак – җиде ел муллыктан соң киләсе җиде еллык кытлык турында сөйли. Төшнең ике тапкыр кабатлануы исә Аллаһының әмере хак икәнне күрсәтә, һәм Ул аны гамәлгә ашырачак».

Аннары Йосыф, фиргавенгә киңәш биреп, зирәк акыллы бер кешене Мисыр җирләре өстеннән идарәче итеп куярга һәм муллык елларында саклык мал тупларга кирәк, диде.

*ЯРАТЫЛЫШ 41:1–36*



## ЙОСЫФ – МИСЫР ИДАРӘЧЕСЕ

Йосыфның төш юравы фиргавен күңеленә хуш килде. Хезмәтчеләренә ул: «Үзендә Аллаһы Рухын йөрткән мондый кешене тагын каян табасың?!» – диде. Йосыфка исә: «Әгәр боларның һәммәсен Аллаһы сиңа ачып биргән икән, димәк, синдәй зирәк акыллы адәм бүтән юктыр, – диде. – Син минем йортымның идарәчесе булырсың. Бар халкым синең сүзне тыңлап эш итәр. Мин сине бөтен Мисыр җире өстеннән идарәче итеп куям, синнән тик минем тәхетем генә бөегрәк булыр».

Шулай дип, фиргавен, үзенең бармагыннан йөзеген салып, Йосыфның бармагына кигезде, муенына алтын чылбыр муенса такты, затлы тукымадан тегелгән киемнәр бирде. Аннары ул Йосыфны бөтен Мисыр җире буйлап йөртеп чыгарга боерды. Юлда барганда халык Йосыфны сәламләсен өчен, фиргавен аны үзенең икенче дәрәҗәдәге арбасына утыртырга кушты.

Шундый югары урынга ирешүгә, Йосыф үзенә йөкләнгән вазифаларны башкарырга кереште. Кытлык чоры җиткәч Мисыр халкы ачтан кырылып бетмәсен өчен, җиде ел дәвамында ул, һәртөрле игеннән мул уңыш җыеп, саклык урыннарына хисапсыз күп азык-төлек туплады.

*ЯРАТЫЛЫШ 41:37–48*



## ҖИДЕ ЕЛГА СУЗЫЛГАН КЫТЛЫК

Җиде ел гомер узганнан соң, бөтен җир йөзендә ачлык башланды. Йосыфтан икмәк сатып алырга өметләнеп, барлык мәмләкәтләрдән халык Мисырга агылды. Чөнки Йосыф Мисырның бөтен калаларында мул итеп азык-төлек тупларга өлгергән иде.

Мисырда икмәк барлыгын белгәннән соң, Ягъкуб, үз янында кече улы Беньяминне генә калдырып, улларының унысын да шунда икмәк сатып алырга җибәрде.

Йосыф исә, Мисырның баш түрәсе сыйфатында, килгән бар халыкка икмәк сата иде. Йосыфның хозурына килгәч, агалары, җиргә кадәр башларын иеп, үзләренә икмәк сатуын үтенделәр. Йосыф үзе агаларын бер күрүдә таныса да, тегеләр аны танымадылар. Чөнки Йосыфны коллыкка сатып җибәргәннән соң, аңардан һичбер хәбәр алганнары булмады; Йосыф шундый дәрәҗәгә ирешкәндер дигән уй исә аларның башына да килмәде.

Йосыф, кардәшләрен танымаганга салышып, аларга: «Сез – чик буйларындагы сакланмый торган ачык урыннарны күзләргә килгән шымчылар!» – дип гаеп ташлады. Кардәшләре исә аңа: «Без намуслы кешеләр, бер атаның балалары, иң кече энебез әтиебез янында калды», – диделәр. Йосыф аларны сак астына алырга боерык бирде. Өч көннән соң агаларына ул болай диде: «Әгәр сез дөрестән дә намуслы кешеләр икән, арагыздан берегез монда калсын, башкаларыгыз ачлыктан интеккән гаиләләрегезгә икмәк алып китсен. Ә инде сүзегезнең хаклыгын исбатлар өчен, кече энегезне минем янга китерегез, шул чагында сезнең бу илгә явыз нийт белән килмәвегезгә ышанырмын».

Бу сүзләрне ишетеп, ир туганнар бер-берсенә: «Теге вакытта энебез Йосыфка кылган гөнаһ эшебез өчен җәза бу, – диештеләр. – Без аның газапларын күреп тордык, ул бездән ялварая-лвара үтенде, әмма без аны тыңламадык. Инде шул эшебез өчен безнең башка да кайгы килде». Йосыф белән тылмач аша сөйләшкәнгә, кардәшләр хәзер Йосыфның бу сүзләрне тыңлап-аңлап торганын белмәделәр. Аларның шушы сүзләрен ишетеп, Йосыф икенче бүлмәгә чыгып китте һәм елап җибәрде. Аннары яңадан алар янына керде дә араларыннан Шимунны аерып алып Мисырда калдырды, башкаларын, капчыкларына икмәк тутырып, өйләренә кайтарып җибәрде.

*ЯРАТЫЛЫШ 41:54–57; 42:1–25*



## ЙОСЫФНЫҢ КАРДӘШЛӘРГӘ ҮЗЕН ТАНЫТУЫ

Өйләренә әйләнеп кайтуга, Йосыфның кардәшләре алар белән ни-нәрсәләр булганны аталарына сөйләп бирделәр. Картлык көнендә үзенең бердәнбер юанычы булган төпчек улы Беньяминне өлкән уллары белән Мисырга җибәрергә Ягъкуб һич кенә дә риза булмады.

Мисырдан алып кайткан икмәк күпмедер вакыттан соң ашалып бетте, һәм Ягъкуб үзенең улларына: «Мисырга барып, тагын икмәк сатып алып кайтыгыз», – диде. Уллары исә: «Мисыр идарәчесе безне, яныгызда кече энегез булмаса, килеп тә йөрмәгез, дип кисәтте», – диделәр. Беньяминне җибәрергә Ягъкуб ризалашмады. Әмма ачлык көчәйгәннән-көчәя барды, һәм ул, балаларына хәерле юл теләп, аларга фатихасын бирде: «Кодрәтле Алла ул адәмнең күңелендә мәрхәмәт хисләре уятсын да, анда тоткарланган кардәшегезне дә, Беньяминне дә ул адәм кире кайтарып җибәрсен иде», – дип теләде Ягъкуб.

Шулай итеп, кардәшләр, Беньяминне алып, Мисыр җиренә килеп җиттеләр. Беньяминне күргәч, йортындагы икенче бүлмәгә чыгып, Йосыф елап алды. Аннары, бит-күзләрен юып, хезмәтчеләренә кунакларны бик шәпләп сыйларга кушты. Йосыфның шулай хөрмәт күрсәтүенә туганнар каушап калдылар. Йосыф исә, күңелендә ташыган уй-хисләрен тыя алмыйча, кычкырып елап җибәрде һәм кардәшләренә: «Мин Йосыф бит! – дип белдерде. – Әтием исән-саумы?» Ләкин кардәшләре авыз ачып бер сүз әйтә алмадылар, чөнки алар тәмам аптырап калган иделәр. «Якынрак килегез әле», – диде аларга Йосыф. Кардәшләре якынлашкач: «Сезнең тарафтан Мисырга сатылган Йосыф мин! – дип сүзен дәвам итте. – Ләкин мине монда сатып җибәрүегез өчен хәсрәт чигеп, үкенеп газапланмагыз, чөнки Раббы мине Мисырга сезнең гомерләрне саклап калыр өчен җибәргән. Кыскасы, мине бирегә сез түгел, ә бәлки Аллаһы җибәрде һәм фиргавенгә мине киңәшче, аның бөтен ил-йорты белән идарә итүче хуҗа, бөтен Мисыр җирләренә хөкемдар итеп кылды. Тизрәк әтием янына кайтыгыз да, улың Йосыф болай дип әйтә, диегез: „Аллаһы мине бөтен Мисыр мәмләкәте җирләренә хөкемдар кылды, вакытны сузмыйча яныма килеп җит; сине монда карап-ризыкландырып торырмын, чөнки кытлык әле тагын биш ел дәвам итәчәк“».

Шулай дип, Йосыф Беньяминне кочаклап алды һәм тагын елап җибәрде. Аннары күз яшьләре түгә-түгә кардәшләренең һәрберсен кочаклап үпте.

*ЯРАТЫЛЫШ 42:36–38; 43:1–34; 45:1–15*



## ЙОСЫФ БЕЛӘН АТАСЫНЫҢ ОЧРАШУЫ

Йосыф янына кардәшләренең килүен ишеткәч, фиргавен аларга юл азыгы, кием-салым, аларның үзләре һәм балалары, шулай ук аталары Ягъкуб өчен җигүле арбалар бирде, чөнки ул аларның барсына да Мисырга күченеп килергә тәкъдим итте.

Өйләренә әйләнеп кайтуга, ир туганнар аталары Ягъкубка Йосыф хакында сөйләп бирделәр. Яраткан улы Йосыфның исән булуын ишеткәч, аталары чиксез сөенде һәм, улы белән күрешер өчен, Мисыр җиренә барырга карар кылды. Шушы хәлләрдән соң Ягъкубка төшендә Аллаһы күренеп: «Ягъкуб! Мин – Аллаһымын, синең атаңның Алласы. Курыкма, Мисырга күченеп кит; Мин анда синнән бөек бер халык тудырырмын. Мин Мисырга синең белән бергә барам. Соңрак сине аннан алып чыгучы да Мин булырмын», – диде.

Ягъкуб, үзенең балаларын, оныкларын ияртеп, бар булган мал-мөлкәтен төяп, Мисыр тарафына кузгалды. Йосыф та, арбасын җиктереп, атасын каршыларга юлга чыкты. Атасын күрүгә ул атлыгып аның муенына барып сарылды һәм кочагында үкси-үкси бик озак елады.

Йосыф янына туганнары күченеп килгәнне ишеткән фиргавен, Йосыфны үз хозурына чакырып алып: «Атаң белән кардәшләрең монда синең янга килгәннәр икән. Бөтен Мисыр иле синең алдыңда – туганнарыңа илнең иң әйбәт җирләрен бир», – диде.

Йосыф шулай үзенең кардәшләренә Мисыр иленең иң яхшы өлешеннән җир биләмәсе бирде, аларны һәрдаим икмәк һәм башка кирәк-ярак белән тәэмин итеп торды.

Кәнган җирләренә Ягъкуб кабат әйләнеп кайтмады, шунда Мисыр илендә калды. Ягъкуб, әҗәле якынлашканны сизеп, Йосыфның уллары Менашше белән Эфраимга һәм үзенең улларына фатихасын бирде. Аталарының вафатыннан соң Ягъкубның уллары ул әйтеп калдырган васыятьне төгәл үтәделәр – аны Кәнган җирендәге Махпела кырында урнашкан ата-бабалар мәгарәсендә, Ибраһим белән Сара, Исхак белән Рәбика янында гүргә иңдерделәр.

*ЯРАТЫЛЫШ 45 – 50*



## ЯНЫП ТОРГАН КҮГӘН КУАГЫ

Байтак еллар узды. Мисыр илендә яшәүче Йосыф токымы өчен авыр заманнар башланды: мисырлылар аларны авыр эш башкарырга мәҗбүр итеп интектерә торган булдылар. Аллаһы исраилиләрне Мисыр коллыгыннан коткарырга хәл кылды һәм әлеге эшкә Муса исемле кешене сайлады. Мусаның Мисырдан ерак булмаган бер чүлдә сарык көтеп йөргән көне иде. Бервакыт ул Хореб дип аталган Аллаһы тавы итәгенә килеп чыкты, һәм шунда янып торган күгән куагы арасында Раббы фәрештәсе пәйда булды. Ялкын телләре чорнап алган куакның янып торуын, әмма янып бетмәвен күреп, Муса: «Барып карыйм әле, нинди сәер нәрсә икән ул, ни өчен куак янып бетми икән?» — дип уйлады.

Муса якынрак килгәч, янып торган куак эченнән Раббының: «Муса! Якын килмә. Аяк киемеңне сал, чөнки син басып торган урын изге җир. Мин — синең ата-бабаларың Ибраһим, Исхак һәм Ягъкубның Алласымын», — дигән тавышын ишетте. Муса, Аллаһыга карарга куркып, йөзен каплады.

«Үз халкымның Мисырда ничек җәфа чигүен күрәм Мин, аның елау-сыктавын, карап эшләтүчеләрдән зарлануын ишетәм, — диде аңа Раббы. — Халкымның авыр кайгысын беләм Мин, шуңа күрә аларны мисырлылар кулыннан азат итәргә барам, аларны шул илдән алып чыгып, сөт белән бал агып торган уңдырышлы, иркен җирләргә ияртеп китәчәкмен. Исраилиләрнең аһ-зарларын ишетәм Мин, мисырлыларның аларны ничек изүен күреп торам. Шулай итеп, бар: Мин сине фиргавен янына җибәрәм. Минем халкым Исраилне син Мисыр җиреннән алып чыгарсың».

Әмма Муса икеләнеп калды, чөнки әлеге бөек бурычны үтәргә ул үзен лаек түгел дип саный иде. Шуңа күрә Аллаһыга ул: «Фиргавен катына барып, Исраил халкын Мисыр җиреннән алып чыгарга ул кадәр кем соң мин?!» — диде. Әмма Аллаһы аңа: «Мин синең яныңда булырмын», — дип җавап бирде.

*ЧЫГЫШ 3:1–12*



## АЛЛАҺЫНЫҢ ИСРАИЛИЛӘРНЕ МИСЫРДАН АЛЫП ЧЫГУЫ

Фиргавен исраилиләргә Мисырдан китәргә рөхсәт итмәгәннән соң, Раббы бөтен Мисыр халкын тугыз тапкыр коточкыч авыр газапларга дучар итте, әмма фиргавен торган саен рәхимсезләнә генә барды, исраилиләрнең Мисырдан китәргә җыенулары белән ул барыбер ризалашмады. Шуннан Раббы унынчы, иң соңгы җәзаны җибәрде: төн уртасы җиткәч, һәрбер Мисыр гаиләсендә беренче булып туган ир бала, шулай ук беренче булып дөньяга килгән ата җенестәге мал-туар да үлеп бетте. Фиргавен шул ук төнне Муса белән Һарунны чакырып алып: «Үзегез дә, бөтен исраилиләр дә, җыенып, бездән аерылып китегез, – диде. – Барыгыз, үзегез әйткәнчә, Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, үзегез белән вак һәм эре терлегегезне дә алып китегез. Миннән риза калып, юлыгызда булыгыз».

Исраилиләр тизрәк җыенып китсен өчен, мисырлылар аларны: «Югыйсә барыбыз да кырылып бетәчәкбез», – дип ашыктырып тордылар.

Исраилиләр Мисыр чикләренә таба юл алды. Балаларны, хатын-кызларны исәпләмәгәндә, җәяүле ирләрнең саны алты йөз мең чамасы иде. Аларга башка кавемнәрдән дә бик күп кеше иярде. Исраилиләр үзләре белән шактый гына вак һәм эре терлекләрен дә куып алып китте.

Мисырдан чыкканда үзләре белән алган камырдан исраилиләр төче көлчә пешерделәр: зур ашыгычлык белән киткәнгә күрә, юлда ашарга башка төрле ризык әзерләп торырга аларның вакытлары булмады.

Исраил халкы Мисыр илендә барлыгы дүрт йөз дә утыз ел гомер итте.

Аллаһы исраилиләрне Кызыл диңгезгә илтүче сахра юлы белән алып китте. Үзенең халкын кай тарафларга алып баруы бары тик Аллаһыга гына мәгълүм иде. Шуңа күрә Ул көндезләрен алар алдыннан болыт баганасы, ә төннәрен исә, юлларын яктыртып, утлы багана рәвешендә барды. Болыт баганасы тукталуга, исраилиләр чатырларын корып ял итә, багана кузгалуга, алар да юлларын дәвам итә иделәр.

Көндезләрен – болыт баганасы, ә төннәрен ут баганасы Аллаһы халкын беркайчан да ташлап китмәде.

*ЧЫГЫШ 12:31–40; 13:20–22*



## ИСРАИЛИЛӘРНЕҢ КЫЗЫЛ ДИҢГЕЗНЕ КИЧҮЕ

Исраилиләрнең Мисырдан үз Алласына корбан китерү өчен генә түгел, ә бәлки бөтенләйгә китүләрен аңлагач фиргавен үзенең бөтен җайдакларын, сугыш арбаларын һәм бар гаскәрен җыеп алар артыннан куа чыкты.

Кызыл диңгез ярларына җитеп туктагач, исраилиләрнең барыр урыны калмады, чөнки эзләренә басып диярлек артларыннан мисырлылар килә иде. Каршыларында җәйрәп яткан диңгезне һәм куа килүче мисырлыларны күреп, Аллаһы халкы: «Безне чүл дәрьясында харап итәр өчен генә Мисырдан алып чыккансың икән!» – дип Мусага гаеп ташлады. Ләкин Муса аларга җавап итеп: «Курыкмагыз! Нык булыгыз һәм шул чагында Раббының сезне ничек итеп коткаруына шаһит булырсыз. Эзегезгә басып килүче мисырлыларны сез бүтән беркайчан күрмәссез. Сезнең өчен Раббы Үзе көрәшәчәк, борчылмагыз», – диде.

Аллаһы шунда Мусага диңгез өстенә кулын сузарга кушты. Муса диңгез өстенә кулын сузуга, Раббы, көнчыгыш тарафыннан көчле җил кузгатып, диңгез суларын кире чигендерде, һәм төн эчендә исраилиләр каршында диңгезнең бер өлеше коры җиргә әйләнде – диңгез сулары икегә аерылган кебек булды. Исраилиләр диңгезне коры җир буйлап кичте, диңгез сулары исә уңнан да, сулдан да дивар сыман булып торып калды.

*ЧЫГЫШ 14:5–22*



## МИСЫР ГАСКӘРЕНЕҢ КЫЗЫЛ ДИҢГЕЗДӘ ҺӘЛАК БУЛУЫ

Исраилиләрне куып килүче мисырлылар да суы чигенгән диңгезгә кереп киттеләр. Иртәнге якта Аллаһы мисырлылар арасында шактый зур ыгы-зыгы куптарды: сугыш арбаларының тәгәрмәчләре ватылып, алар инде алга бара алмадылар. Шушы хәлләрне күреп торган гаскәриләр бер-берсенә: «Әйдә исраилиләрдән качыйк, чөнки Раббылары безгә каршы алар ягында сугыша», – диештеләр.

Аллаһы халкы коры җирдән барган сыман диңгезне кичеп чыкканнан соң, Раббы Мусага: «Кулыңны диңгезгә таба суз, барча арбалары һәм җайдаклары белән бергә мисырлылар су астында калсын», – диде. Муса Раббы кушканча эшләде, һәм диңгез сулары әүвәлге хәленә кайтып, мисырлыларның барысы дулкыннар эчендә үзенең әҗәлен тапты.

Әнә шулай итеп Аллаһы ул көнне Үзенең халкын коткарды. Мисырлыларны һәлакәткә дучар иткән Раббының кодрәтен үз күзләре белән күргән исраилиләр, Аңардан куркып, Аны олыладылар, бөтен өметләрен Аңа һәм Аның хезмәтчесе Мусага багладылар. Шуннан Муса, бар халык белән бергә бөек Коткаручыны данлап, тантаналы җыр башкарды:

> Раббы – миңа көч бирүче һәм минем даным; Ул мине коткарды. Ул – минем Аллам, һәм мин Аңа дан җырлыйм. Синең уң кулың, Раббы, үзенең көче белән дан яулады; Синең кулың, Раббы, дошманны тар-мар итте. Тиңдәшсез зур шөһрәтең белән Син Үзеңә каршы күтәрелгән адәмнәрне юк иттең. Илаһларның кайсысы Синең белән тиңләшә ала, и Раббы?! Кем Синең кебек могҗизалар кыла ала?! Кем шулай Синең кебек изге?! Һәм кемнең даны шулай куркуга төшерә ала?! Раббы мәңге хакимлек итәчәк.

*ЧЫГЫШ 14:23–31; 15:1–18*



## УН БОЕРЫК

Муса – Аллаһы тарафыннан сайлап алынган, Аның тугры, тыңлаучан хезмәтчесе иде. Шуңа күрә Раббы халык белән һәрчак Муса аша сөйләште.

Чүл буйлап сәфәр кылучы Исраил халкы Синай тау итәгенә килеп туктагач, Муса тау башына күтәрелде. Анда аңа Раббы зур булмаган, такта сыман ике яссы таш тапшырды. Әлеге ташларда Аллаһы халкы төгәл үтәргә тиешле Ун боерык язылган иде:

> Мин – Раббы, синең Аллаһың. Мин сине, коллыктан азат итеп, Мисыр җиреннән алып чыктым. Миннән башка синең һичнинди аллаң булырга тиеш түгел.
>
> Күкләр киңлегендә, җир өстендә яки су астында яшәүче җан ияләренең сурәтләреннән потлар ясама; аларга баш имә һәм табынма.
>
> Раббы Аллаңның исемен кирәксезгә кулланма; әгәр кемдер Аның исемен урынсызга куллана икән, Раббы аны җәзасыз калдырмас.
>
> Шимбә көннең изге көн булуын исеңдә тот. Алты көн буе эшлә һәм бөтен эшләреңне башкар, җиденче – шимбә көнне исә Раббы Аллаңа багышла.
>
> Раббы Аллаң сиңа биргән җирдә гомерең озын булсын дисәң, ата-анаңны хөрмәт ит.
>
> Кеше җанын кыйма.
>
> Зина кылма.
>
> Урлашма.
>
> Башка берәүгә каршы ялган шаһитлык бирмә.
>
> Башка берәүнең йортына, хатынына, ир яки хатын-кыз колына, үгезенә яисә ишәгенә, гомумән, аның малына нәфесеңне сузма.

*ЧЫГЫШ 20*



## КҮЗӘТЧЕЛӘРНЕҢ КӘНГАНГА КИЛҮЕ

Синай чүле буйлап озакка сузылган, ялыктыргыч сәфәрдән соң исраилиләр, ниһаять, Кәнган җирләренә килеп җиттеләр. Муса: «Әлеге илнең көньяк өлешенә барып, аның ниндиерәк җир булуын һәм анда нинди халык яшәгәнне, ул халык куәтлеме, юкмы икәнне, шәһәрләренең ниндилеген күреп-белеп кайтыгыз. Шул җирдә үскән җиләк-җимешләрне алып кайтырга тырышыгыз», — дип, исраилиләрнең унике ир-егетен Кәнган якларына озатты. Шулай итеп, унике күзәтче юлга кузгалды һәм кырык көн дәвамында Кәнган җирен карап-күзәтеп йөрде. Кире әйләнеп кайтканда алар инҗир, анар, башка төр җимешләр, шулай ук бик зур йөзем тәлгәше алып кайттылар; ул тәлгәшне таякка элеп ике кеше күтәргән иде. Күзәтчеләр әлеге илнең, дөрестән дә, «сөт һәм бал агып торган» җирдә урнашуын сөйләделәр. Ә халкы аның хәйран көчле, һәм алар зур, ныгытылган шәһәрләрдә яши, диделәр. «Без аларга каршы сугышыр хәлдә түгелбез, чөнки әлеге халык бездән көчлерәк», — диде алар.

Аллаһының Үз халкына ярдәм кулы сузарга вәгъдә итүен онытып, күзәтчеләр Кәнган иле турындагы сүзләре белән исраилиләр күңеленә шом салдылар. Күзәтчеләрдән бары ике кеше, Нун улы Иешуа һәм Кәлеб кенә Раббыларына тугрылык саклап, халыкны куркуга төшерергә теләмәде. «Без барып әлеге илне яулап алырга тиешбез, чөнки безнең кулдан килердәй эш бу», — диде Кәлеб. Әмма халык аларның сүзенә колак салмады, һәммәсе зарланып еларга, аларны Мисыр иленнән алып чыккан Муса белән Һарунны битәрләргә тотынды. Аннары алар бер-берсенә: «Үзебезгә башка юлбашчы сайлыйк та кабат Мисырга әйләнеп кайтыйк», — диешә башладылар. Нун улы Иешуа белән Кәлеб исә, ачудан киемнәрен ертып, халыкка болай диделәр: «Раббы безне мәрхәмәтеннән ташламас, сөт һәм бал агып торган әлеге җирләрне безнең кулга тапшырыр. Раббыга каршы килмәгез һәм ул җирләрдә яшәүче халыктан курыкмагыз, чөнки алар безнең кулга төшәчәк: аларның яклаучысы юк, ә безнең якта — Раббы, курыкмагыз алардан». Муса белән Һарун, халыкның вәсвәсәле сүзләрен ишетеп, борчуга калдылар — исраилиләрнең үҗәтлеген һәм ышанмауларын күрү аларга авыр иде. Шунда Аллаһы Мусага болай диде: «Тагын кайчанга кадәр бу халык Минем ачуымны китерер икән? Мин кылган байтак могҗиза һәм галәмәтләрне күреп тә, тагын кайчанга кадәр Миңа ышанмаслар икән?»



Шуннан Аллаһы, исраилиләрне кырып бетереп, Мусадан яңа бер халык тудырырга әзер булуын әйтте, әмма Муса, ялыныпялварып, исраилиләрнең бу зур гөнаһын кичерүне үтенде. Муса хакына Аллаһы әлеге буйсынмас халыкны тагын гафу итте. «Әмма, – диде Ул, – Миңа ышанмаган өчен исраилиләрнең киләчәк буыны гына, вәгъдә ителгән Кәнган җирләренә кереп, шунда яши башлар. Исраилиләрнең хәзерге буыныннан бары тик Нун улы Иешуа һәм Кәлеб кенә анда аяк басар, чөнки алар Миңа тугры булып калдылар».

*САННАР 13:1–34; 14:1–30*

## ДАВЫТ – ИСРАИЛ ПАТШАСЫ

Исраилиләр Кәнган җирләренә килеп урнаштылар. Күпмедер вакытлар узганнан соң, алар, безнең өстән патша идарә итәргә тиеш, дип хәл кылдылар. Исраил патшалары арасында иң танылганы – Аллаһы Үзе сайлап куйган Давыт.

Бөтен Исраил җиренең патшасы итеп билгеләнгәннән соң, ул үзенең тәхетен Иерусалим шәһәрендә урнаштырды. Аллаһыдан акыл-зирәклек һәм көч бирелгәнгә күрә, Давыт Исраилнең бөтен дошманнарын кырып бетерә алды. Давыт патша Раббыны бик олылый иде, шунлыктан Аллаһының «Ун боерыгы» язылган яссы ташлар саклана торган сандыкны, ягъни Аллаһы сандыгын үз шәһәренә алып кайтырга ниятләде. Заманында әлеге сандыкны фәләстыйнлеләр сугыш кырында кулга төшереп үзләре белән алып киткән булалар. Соңрак алар аны исраилиләргә кабат кайтарып бирәләр, һәм шуннан соң сандык Кыръят-Ягарим дип аталган урында Амминадаб исемле бер кешенең йортында калган була. Давыт аны Иерусалим каласына күчерергә карар кыла.

Сандыкны алып кайтыр өчен, Давыт үзе белән утыз мең кеше ияртеп барды. Сандыкны Иерусалимга алып кайтып Сион тавына урнаштырган мәлдә Давытның күңеле тантана итте. Гөсләдә уйнап, ул мәрхәмәтле Аллаһыга дан-шөһрәт яудырды, шатлыгыннан биеде. Аның белән бергә бар халык сөенешеп Аллаһыны данлады, быргылар уйнатты. Махсус эшләнгән чатыр эченә Аллаһы сандыгын алып кереп урта бер җиргә урнаштырганнан соң, Давыт Раббыга багышлап күп санлы корбаннар китерде. Корбан китерү йоласын башкаргач, ул, күкләр Хуҗасы Раббы исеменнән халыкны фатихалап, исраилиләрнең һәммәсенә икмәк, көлчә һәм кыздырган ит өләшеп чыкты.

Давыт патша токымының киләчәген кайгыртырга вәгъдә итеп, Раббы аның нәсел варисы турында болай диде: «Мин – аның атасы, ул Минем улым булыр. Әгәр ул гөнаһ эш кылса, Мин аңа җәзаны башкалар кулыннан бирдерермен. Ләкин синең хакка Мин, кайчандыр Шаул патшадан йөз чөергән кебек, аны беркайчан Үземнең рәхим-шәфкатемнән аермам. Синең нәселең һич какшамас булыр, синең патшалыгың һәм синең тәхетең Минем каршыда мәңге торыр». Раббының бу сүзләрен Давытка Натан пәйгамбәр җиткерде. Әлеге сүзләрне ишеткәннән соң Давыт, Раббы каршына килеп, болай диде: «И-и Раббым минем, Син мине

шулай күтәрерлек кем мин ул кадәр?! Минем гаиләм дә Синңа ни өчен шулай мөһим?! Ничек бөек Син, Раббым! Синең белән тиңләшердәй һичбер зат юктыр, Синнән башка бүтән алла да юк. Инде хәзер, Раббы Аллам, Үзеңнең колың һәм аның нәселе турындагы сүзләреңне мәңгегә ныгытып куй һәм әйткәннәреңне тормышка ашыр».

*ПАТШАЛАР ТУРЫНДА ИКЕНЧЕ КИТАП 6:2–19; 7:14–16, 18–29*



## АЛЛАҺЫ ЙОРТЫ

Давыт патшага Аллаһы: «Миңа багышланган йортны синең улың Сөләйман төзер. Раббы шөһрәте шунда балкып торыр», – дип әйткән була.

Раббының боерыгын үтәп, Сөләйман Аңа күзнең явын алырлык гүзәл бина төзетте. Йортның диварлары эчке яктан саф алтын белән каплап алынган булып, яктырткычлар нурында бар нәрсә балкып-җемелдәп торды. Аллаһы йорты тирәли Сөләйман, таш дивар белән әйләндереп алып, ишегалды ясатты. Ишегалдына, корбанлык малны юар өчен дип, бакырдан коелган ун зур чан куйдырды. Тагын берсе, башкаларыннан шактый күләмлерәк булып, бакырдан коелган унике үгез сыны өстенә куелган иде. Чанның монысы руханилар, коенып, пакьләнер өчен иде. Корбан китерү өчен ишегалдында шулай ук бакырдан зур итеп мәзбәх эшләнде. Йорт эчендә исә, Аллаһы сандыгын урнаштырыр өчен, саф алтын белән тышланган Иң изге бүлмә булдырылды. Хуш исле сумала-майлар төтәсләү өчен, Изге йортның алгы бүлмәсендә алтыннан коелган махсус өстәл урнаштырылды. Иң изге саналган түр бүлмәгә, зәйтүн агачыннан юнып, алтын йөгертелгән ике зур керубим сыны, ягъни Аллаһы хезмәтендәге рухи затлар сыны куелды. Аларның канатлары як-якка җәелгән булып, берсенең бер канат очы – бер диварга, икенчесенең дә бер канат очы каршыдагы диварга орынып тора, ә икенче канатларының очлары исә бүлмә уртасында бер-берсе белән килеп тоташа иде.

Аллаһы йортының диварлары керубимнәр, хөрмә агачлары һәм ачылып килүче чәчәк сурәтләре белән бизәлде. Аллаһы йортының идәне шулай ук алтын белән капланды.

*ПАТШАЛАР ТУРЫНДА ӨЧЕНЧЕ КИТАП 6:14–36*




## МӘЛИКӘ ЭСТЕР

Күп гасырлар үтте, яһүдләрнең күпмедер өлеше, таралышып, төрле илләргә һәм калаларга китеп төпләнде. Ул заманнарда Фарсы дәүләте иң көчлеләрдән санала иде.

Фарсы патшасы Артахшаста, өйләнергә карар кылганнан соң, бөтен чибәр кызларны башкала Шушанга җыярга әмер биреп патшалыгының төрле тарафларына үзенең чапкыннарын җибәрде. Сайлап алынган кызларны патша хозурына кертер алдыннан унике ай дәвамында әзерләргә тиеш иделәр. Кайчандыр Ашшур һәм Бабил гаскәрләре тарафыннан әсир ителгән яһүдләрнең нәсел-нәсәбе ул заманнарда Фарсы җирендә яшәп, алар арасында Мәрдәкәй атлы бер кеше дә бар иде. Шушы Мәрдәкәй үзенең вафат булган абзасының Эстер исемле чибәр, зифа буйлы кызын тәрбияли иде. Кызның ата-анасы үлгәннән соң, Мәрдәкәй аны үз баласыдай карады-бакты. Патшалыктагы гүзәлләрне башкалага җыя башлагач, Эстер дә патша йортына чакырылды, һәм кызлар арасында патшага иң ошаганы ул булды. Артахшаста Эстернең башына патша таҗы кидерде һәм аны мәликә итте, аннары аның хөрмәтенә барлык түрәләрне һәм үз хезмәтендәге кешеләрне зур мәҗлескә җыйды, өлкәләргә ташламалар ясады һәм, патшаларча юмартлык күрсәтеп, байтак кына бүләкләр өләште. Эстер исә, Мәрдәкәй кушканча, чыгышы белән үзенең нинди халыктан булуы турында берни әйтмәде.

Шушы хәлләрдән соң күпмедер вакыт узгач, Артахшаста патша үзенең түрәләреннән берсен – Һәмән исемле кешене – калган барлык түрәләрдән өстен итеп куйды. Патша сараенда хезмәт итүчеләрнең һәммәсе, патша боерганча, Һәмән каршында җиргә кадәр иелеп баш орырга тиеш иделәр. Бары тик Мәрдәкәй генә аның алдында тез чүгәргә, йөзе белән җиргә капланырга теләмәде. Һәмәннең аңа бик нык ачуы чыкты, һәм ул Артахшаста патшалыгындагы бөтен яһүдләрне кырып бетерергә ният корды.

Бервакыт Артахшаста патшага ул: «Синең патшалыкның бөтен төбәкләрендә төрле халыклар арасына таралып-сибелеп яшәүче бер кавем бар; ул кавемнең кануннары башка барлык халыкларныкыннан үзгә, һәм алар патша чыгарган кануннарны үтәмиләр», – диде. Патша әлеге Һәмәнгә яһүдләр белән үзе теләгәнчә эш итәргә рөхсәт итте. Озак та үтми, «уникенче айның, ягъни Адар аеның унөченче көнендә, барлык яһүдләр – яше-карты,



бала-чагасы һәм хатын-кызы – бер көн эчендә үтерелергә, һәлак ителергә, юкка чыгарылырга, аларның мал-мөлкәте исә таланырга тиеш» дип язылган хатларны чапкыннар Фарсы патшалыгының барлык төбәкләренә таратты. Артахшаста патша фәрманы килеп ирешкән һәр җирдә яһүдләр, ураза тотып, ачы күз яшьләре түктеләр.

*ЭСТЕР 1 – 3*

## МӘЛИКӘ ЭСТЕР

***(дәвамы)***

Бу турыда белгәннән соң, Мәрдәкәй, патша әмере турында мәликә Эстергә хәбәр җибәреп, аңа патша янына керергә һәм үз халкы өчен ялварырга, мәрхәмәт күрсәтүен сорарга кушты. Үзенең хезмәтчесе аша Эстер Мәрдәкәйгә: «Чакырылмаган килеш патша хозурына кергән кешене бер хөкем – үлем көтә. Патша үзенең алтын таягын төбәп күрсәткән кеше генә исән кала. Ә минем утыз көн инде патша хозурына чакырылганым юк», – диде. Моңа каршы Мәрдәкәй: «Бөтен яһүдләр арасыннан берүзең генә патша сараенда котылып калырмын дип өметләнмә. Кем белә, бәлки нәкъ менә шушындый бер вакыт өчен син мәликә дәрәҗәсенә ирешкәнсеңдер дә», – дип хәбәр җибәрде. Мәрдәкәйгә җавабында Эстер болай язды: «Бар, Шушанда булган барлык яһүдләрне җый, һәм минем хакка ураза тотыгыз, өч тәүлек буе көндезен дә, төнлә дә ашамагыз-эчмәгез. Шулай ук мин дә үземнең хезмәтче кызларым белән ураза тотармын. Шуннан соң, гәрчә канунга каршы булса да, патша хозурына керермен; инде һәлак булырга язган икән – һәлак булырмын». Ул арада исә явыз Һәмән, Мәрдәкәйне асарга дип, егерме биш метр биеклектәге дар агачы ясатып куйды.

Өченче көн дигәндә Эстер, мәликәчә киенеп, патша сараеның эчке ишегалдына, патша бүлмәсенә керде. Патша исә кулындагы алтын таягын Эстергә таба сузды. Эстер, патшага якынлашып, таякка орынды һәм патша белән Һәмәнне үзенә мәҗлескә чакырды. Патша белән Һәмән шул көнне үк мәҗлескә килделәр. Шәраб эчеп кәефләнеп утырган вакытта патша: «Нинди үтенечең бар иде, мәликә Эстер? Теләгең нинди?» – дип сорады. «Теләгем, үтенечем шулдыр: халкым белән бергә минем җанымны да харап итмәскә боерсаң иде. Чөнки безне саттылар – мине дә, халкымны да үтерергә, кырып бетерергә, юкка чыгарырга ният кылалар», – диде. Патша, шул рәвешле, хатынының яһүд икәнен белде, һәм түрә Һәмәннең явыз нияте фаш ителде. Патшаның әмере буенча Һәмәнне Мәрдәкәйгә дип әзерләнгән дар агачына астылар.

Әмма Фарсы патшалыгында яшәүче яһүдләрне юк итү турында патша исеменнән язылган һәм йөзек белән мөһерләнгән хатны, кабул ителгәнчә, гамәлдән чыгару да, үзгәртү дә мөмкин булмастай эш иде. Шуннан, патша боерганча, яңа күрсәтмә язылды: патша яһүдләргә бергә тупланырга һәм гомерләрен саклар өчен



әзер булырга рөхсәт бирде. Патшаның Һиндстаннан алып Хәбәшстан җирләренә кадәр сузылган йөз егерме җиде төбәгенә җитез атларда чапкыннар озатылды, һәм озакламый патшаның әлеге боерыгы барлык өлкәләрнең җитәкчеләренә җиткерелде. Яһүдләрнең шушы зур афәттән котылу хөрмәтенә Мәрдәкәй ел да уздырылырга тиешле Пурим бәйрәмен игълан итте.

*ЭСТЕР 4 – 10*

## ЮНЫС ПӘЙГАМБӘР

Бервакыт Юныс пәйгамбәргә Аллаһы болай диде: «Ниневәгә барырга җыен, шул бөек каланың халкын кисәт, чөнки Миңа андагы явызлыклар турында хәбәр килеп ирешге». Әмма Юныс, Аллаһы сүзенә колак салмыйча, Аңардан качып, Таршиш каласына китәргә карар кылды һәм, Яфу шәһәренә килеп, Таршишка баручы корабка утырды. Әмма Раббы көчле җил кузгатып, диңгездә купкан давылдан кораб аздан гына батмый калды. Котлары алынган диңгезчеләрнең һәркайсы үз илаһына ялварырга тотынды. Корабны җиңеләйтмәкче булып, алар төялгән йөкләрен диңгезгә ыргыта башладылар. Бу вакытны Юныс корабның аскы катында йоклап ята иде. Кораб хуҗасы Юнысны уятып: «Ничек йоклый аласың син? Тор әйдә! Илаһыңа ялвар, бәлки безне ул коткара алыр», – диде. Диңгезчеләр исә: «Әйдәгез жирәбә салыйк: кем аркасында башыбызга шушы бәла төште икән?» – диде. Жирәбә Юныска чыкты. «Диңгезгә ташлагыз мине, – диде аларга Юныс, – шул чагында диңгез тынар, чөнки минем аркада сез шушы давылга эләктегез». Юнысны суга ыргытуга, диңгез шундук тынып калды, һәм корабтагылар, куркуларыннан дер калтырап, Раббы хөрмәтенә корбан китерделәр, нәзерләрен әйттеләр. Аллаһы исә гаҗәеп зур балыкка Юнысны йотарга боерды, һәм балык карынында ул өч көн, өч төн буена һич туктамый үзенең Раббы Алласына дога кылды. Шуннан Раббы әлеге балыкка Юнысны коры җиргә төкереп ташларга әмер бирде.

Юныс пәйгамбәргә Аллаһы икенче кат Үзенең сүзен ирештерде: «Ниневәгә барырга кузгал, шул бөек калага барып, Мин кушканча, халыкны кисәт». Бу юлы Юныс, Аллаһыга каршы килергә кыймыйча, Ниневәгә юл тотты. Шәһәргә килеп җиткәч, ул урамнарда халыкны үгетләп йөрде: «Кырык көннән Ниневә хәрабә хәленә киләчәк!» – диде ул. Бу турыда ишеткәннән соң, Ниневә патшасы, сараеннан чыгып, өстендәге патша киемнәрен салып ташлады да тупас тукымага төренде, халыкка да тупас кием кияргә, ураза тотарга, кылган гөнаһлары өчен ярлыкау сорап Аллаһыга ялварырга кушты. Шәһәр халкы Аллаһының пәйгамбәр аша җиткергән сүзенә ышанды. Раббы исә, Ниневә халкының явызлык кылудан туктавын күреп, рәхим-шәфкать кылды – алдагы ниятеннән кире кайтып, алар өстенә бәлақазалар җибәрмәде.

*ЮНЫС ПӘЙГАМБӘР 1 – 3*



## МӘСИХНЕҢ КИЛҮЕ ТУРЫНДА ПӘЙГАМБӘРЛЕК СҮЗЛӘРЕ

Әлеге китапның башында Аллаһының кешене Үз сыйфатында, Үзенә охшатып бар итүе турында языла. Аллаһы кешенең дә Үзе кебек үк мәрхәмәтле, гадел, гөнаһлардан азат булуын тели. Әмма беренче кешеләр үк инде – Адәм белән Һава – гөнаһка каршы тора алмыйлар. Аларның беренче уллары Кабил үзенең ир туганы Һабилнең җанын кыя. Озакламый җир йөзе шул дәрәҗәдә гөнаһка бата ки, Раббы хәтта: «Һәммәсе юлдан язган, бозыклыкка бердәй баткан; игелек кылучы күренми, һичкем юк!» – дип әйтергә мәҗбүр була.

Раббыга, Хак Аллаһыга тугрылык сакласын, Аның кануннары буенча яшәсен өчен, Аллаһы җир йөзендәге халыклар арасыннан берсен – Исраил халкын сайлап ала. Үзенең пәйгамбәрләре аша Ул Исраил халкына Коткаручының – Аллаһы тарафыннан сайланган Затның, ягъни Мәсихнең дөньяга киләсен алдан әйтеп куя. Ишагыйя пәйгамбәр Гайсә Мәсих туганчы җиде йөз ел алдан болай дип әйтә: «Менә, безнең өчен бер сабый бала туды: угыл бүләк ителде безгә; аның иңендә хакимлек булачак, һәм аңа Гаҗәеп Киңәшче, Кодрәтле Аллаһы, Мәңгелек Ата, Иминлек Хакиме дигән исем биреләчәк». Михә пәйгамбәр исә Мәсихнең кайсы төбәктә туасын да әйтеп куя: «Ләкин син, Эфратадагы Бәйт-Лехем, Яһүдия шәһәрләре арасында иң кечкенәсе булсаң да, Исраил белән идарә итәсе зат синдә туачак. Аның нәсел-нәсәбе ераклардан, бик борынгыдан киләдер».

Ишагыйя пәйгамбәр китабыннан без Мәсихнең дөньяга килүенең төп максатын беләбез: Мәсих кешелекне гөнаһ коллыгыннан коткару, адәм балаларына Аллаһыга йөзләре белән борылырга ярдәм итү һәм, кешеләр кылган гөнаһ өчен үлемгә барып, аларны йолып алу өчен килә. Үзенең пәйгамбәре аша Раббы болай ди: «Минем тәкъва* колым күпләрне аклаячак, аларның гөнаһларын үз өстенә алачак».

Алдан күреп әйтелгән бу сүзләрнең һәммәсе Гайсә Мәсих җиргә килгәннән соң чынга аша. Китапның икенче өлешендә Гайсәнең тууы, Аның тормышы һәм тәгълиматы, Аның үлеме һәм үледән терелүе турында сөйләнә.

*ЗӘБУР 13:3; ИШАГЫЙЯ 9:6; 53:4-12; МИХӘ 5:2*

---

* *Тәкъва – гөнаһ эшләрдән саклана торган, диндар кеше.*



## ГАЙСӘНЕҢ ТУУЫ ХАКЫНДА ЯХШЫ ХӘБӘР

Аллаһы Тәгалә, адәм балаларын гөнаһ һәм үлем коллыгыннан коткарыр өчен, дөньялыкка Үзенең Улы Гайсә Мәсихне җибәрде. Ул туганнан соң, Җирдә яңа дәвер башланды. Еллар исәбен дә без Гайсә Мәсих туган көннән саныйбыз.

Гайсәнең дөньяга килүе гаҗәп кызык. Ул – Аллаһы Улы – терлек абзарында туа. Гайсә туып күпмедер вакыт үтүгә, Һируд патша Аны үтерергә карар кыла...

Әмма барысын да тәртип буенча сөйлик. Исраил иленең төньяк тарафында урнашкан кечерәк кенә Насара шәһәрендә саф йөрәкле, ихлас күңелдән Аллаһы Тәгаләгә бирелгән Мәрьям исемле кыз яши иде. Беркөн аның янына Аллаһы Үзенең фәрештәсе Җәбраилне җибәрде. Мәрьям янына килеп, ул: «Иминлек сиңа! Аллаһының мәрхәмәтен кабул итүче син. Раббы синең белән!» – диде. Фәрештәне күреп, аның сүзләрен ишетеп, Мәрьям уңайсызланып китте. Әмма фәрештә аңа болай диде: «Курыкма, Мәрьям! Аллаһы сиңа Үзенең мәрхәмәтен кылды; син буйга узарсың һәм Ир бала табарсың, Аңа Гайсә* дип исем кушарсың. Ул бөек булыр һәм Аллаһы Улы дип аталыр. Раббы Алла Аңа борынгы бабасы Давытның тәхетен тапшырыр, һәм Ул Ягъкуб халкы өстеннән мәңге патшалык итәр, патшалык итүенең ахыры-азагы булмас».

Ул вакытны Мәрьям Йосыф исемле бик тәкъва кешегә ярәшелгән иде. Фәрештәгә Мәрьям: «Ничек алай булыр икән? Мин бит әле кияүдә түгелмен», – диде. Җәбраил аңа җавап итеп: «Сиңа Изге Рух иңеп, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте төшәр, шуңа күрә синнән туачак Бала изге булыр һәм Аллаһы Улы дип аталыр», – диде. «Мин – Раббы колымын, син ничек әйтсәң, шулай булсын», – дип җаваплады Мәрьям. Шуннан фәрештә аның яныннан китеп барды.

Мәрьямнең балага узганын белгәннән соң, Йосыф ярәшүне өзәргә теләде, әмма төшендә аңа Раббы фәрештәсе күренеп: «Давыт нәселеннән булган Йосыф, Мәрьямне хатынлыкка алырга курыкма, чөнки аның карынындагы Бала – Изге Рухтан. Мәрьям Ир Бала табар һәм син Аңа Гайсә дип исем кушарсың, чөнки Үз халкын Ул алар кылган гөнаһлардан йолып алачак», – диде.

*МАТТАЙ 1:19–21; ЛУК 1:26–35, 38*

---

* *Гайсә – яһүдчә «Раббы коткара» дигән мәгънәдә.*



## ГАЙСӘ МӘСИХНЕҢ ТУУЫ

Мәрьям авырлы вакытта аңа Йосыф белән бергә ерак юлга кузгалырга туры килә, чөнки Рим патшасы Август империядә яшәүче бөтен халыкның исәбен алырга боера. Шул сәбәпле, исемлеккә теркәлер өчен, һәр кеше ата-бабаларының шәһәренә, туган төбәгенә кайтырга тиеш була. Йосыф исә меңел элек Исраилдә идарә иткән Давыт патша нәселеннән иде.

Шул рәвешле, Йосыф белән Мәрьям Давыт патшаның каласы Бәйт-Лехемгә юл алдылар. Насара шәһәре белән Бәйт-Лехем арасы ике йөз чакрымнан артык иде. Ул заманнарда әле поездлар да, автомобильләр дә булмаганга, аларның сәфәре берничә көнгә сузылды. Насара шәһәре Исраилнең төньягында, Гәлиләя өлкәсендә, Бәйт-Лехем исә көньяк тарафта – Яһүдия җирендә урнашкан иде. Гәлиләядән Яһүдиягә бару өчен, алар Самарея төбәген узарга тиеш булдылар; өстәвенә, Самарея белән Яһүдия таулы өлкәләр иде.

Йосыф белән Мәрьям озын юл үтеп Бәйт-Лехемгә аяк басканда, кунакханәләрдә буш урыннар калмаган, ә Мәрьямнең инде бала табар вакыты җиткән иде. Бу хакта Инҗилдә: «Мәрьям үзенең беренче баласын – Ир Бала тудырды һәм Аны биләүләп утлыкка салды», – дип укыйбыз. Димәк ки, алар төн кунарга терлек абзарында тукталган булалар, ә Сабыйны маллар өчен куелган утлыкка салалар. Борынгы риваятьләр буенча, әлеге абзар тау куышында урнашып, ул якларда көтүчеләр андый куышларга төнгелеккә мал-туарны куып кертә торган булганнар.

*ЛУК 2:1–7*



## ГАЙСӘНЕҢ ТУУЫ ХАКЫНДА ФӘРЕШТӘЛӘРНЕҢ КӨТҮЧЕЛӘРГӘ ХӘБӘР ИТҮЕ

Бу вакытны Бәйт-Лехем тирәсендә көтүчеләр үзләренең сарыкларын көтә иде. Аларның кайберләре, Гайсә туасы төнне уяу булып, үзләренең көтүен саклый иде. Бервакыт кинәт алар каршысында Раббы фәрештәсе пәйда булып, Раббы шөһрәтеннән әйләнә-тирә балкып китте. Моны күреп, көтүчеләрнең коты алынды. Әмма фәрештә аларга: «Курыкмагыз! Мин сезгә куанычлы хәбәр – бар халык өчен зур шатлык алып килдем: бүген Давыт шәһәрендә сезнең Коткаручыгыз туды, Ул – Мәсих, Хуҗа-Хаким. Сезгә менә шундый билге: утлыкта яткан биләүле Баланы күрерсез», – диде. Шулчакны фәрештә янында: «Күкләрдәге Аллаһыга дан-шәрәфләр яусын! Аллаһы илтифат күрсәткән кешеләргә җирдә иминлек булсын!» – дип Аллаһы Тәгаләне данлаучы күп санлы башка фәрештәләр күренде.

*ЛҮК 2:8–14*



## МИСЫРГА КАЧУ

Һируд патша идарә иткән заманда, Яһүдиянең Бәйт-Лехем шәһәрендә Гайсә туганнан соң, кояш чыккан яклардан Иерусалимга акыл ияләре – йолдызчылар килеп: «Яһүдиянең яңа туган патшасы кайда? – дип сорадылар. – Көнчыгышта Аның йолдызын күреп, Бала алдында баш иярга дип килдек».

Бу хакта ишеткәч, Һируд патша хафага төште, барлык баш руханиларны һәм Канун белгечләрен җыеп, алардан: «Мәсих кайда туарга тиеш?» – дип сорады. «Яһүдия җирендәге Бәйт-Лехем шәһәрендә, – диде алар, – чөнки Раббы Үзенең пәйгамбәре аша: „Әй син Яһүдия җирендәге Бәйт-Лехем, Яһүдиянең бөек калаларыннан син һич тә ким түгелсең, чөнки синдә Юлбашчы туачак, Ул Минем Исраил халкымның Көтүчесе булачак“, – дип әйткән». Шуннан Һируд йолдызчыларны яшертен генә чакыртып китерде дә алардан йолдызның төгәл калыккан вакытын белеште һәм, аларны Бәйт-Лехемгә җибәреп: «Барыгыз, Бала хакында барысын да җентекләп белешегез. Аны тапкач, миңа хәбәр итегез, мин дә Аңа баш иярга барырмын», – диде. Чынлыкта исә Һируд патша Баланы үтерергә карар кылды, чөнки тора-бара Ул тәхетемне алыр дип курыкты.

Патшаны тыңлап бетергәннән соң, йолдызчылар юлга чыктылар һәм, Бәйт-Лехемгә килеп җитеп, Бала каршында баш иделәр. Төшләрендә, Һируд янына кабат кайтмаска дип, Аллаһыдан кисәтү алганнан соң, алар башка юлдан үз илләренә кайтып киттеләр. Йолдызчыларның алдавын белеп, Һирудның бик нык ачуы килде. Шуннан ул Бәйт-Лехемдә һәм аның әйләнә-тирәсендәге ике яшьлек һәм аннан кечерәк, ягъни йолдызчылардан сорашып белешкән вакытта туган бөтен ир балаларны үтерергә гаскәриләрен җибәрде. Гаскәриләр, Бәйт-Лехемгә килеп, гаепсез сабыйларның җаннарын кыйдылар.

Һируд патша уйлаганча, җаннары кыелган шул балалар арасында йолдызчылар «Исраилнең булачак патшасы» дип әйткән сабый да булырга тиеш иде. Әмма аның өмете акланмады. Акыл ияләре китүгә, Раббы фәрештәсе, Йосыфка төшендә күренеп: «Тор да, Сабый белән Аның анасын алып, Мисырга кач; Мин әйткәнчегә кадәр шунда кал, чөнки Һируд Баланы табып үтерергә ниятли», – дип әйтә. Йосыф, торып, Сабый белән Аның



анасын ала да төнлә Мисыр тарафына чыгып китә һәм Һирудның үлеменә кадәр шунда яши. Бу исә Раббы пәйгамбәре аша: «Үземнең Улымны Мин Мисырдан чакырып алдым», – дип әйтелгән сүзләр гамәлгә ашсын өчен булды.

*МАТТАЙ 2:1–16*

## ГАЙСӘНЕҢ НАСАРАДА ҮТКӘРГӘН БАЛАЛЫК ЕЛЛАРЫ

Һируд патша исән чакта Йосыф, Мәрьям һәм Сабый бала Гайсә Мисырда кала бирделәр. Һируд дөнья куйганнан соң, Раббы фәрештәсе, кабат Йосыфның төшенә кереп: «Тор әйдә, Бала белән Аның анасын алып, Исраил җиренә кайт, чөнки Сабыйның җанын кыярга теләүчеләр инде үлде», – диде.

Йосыф, фәрештә сүзенә буйсынып, Исраил иленә юл алды. Әмма Яһүдиядә Һируд урынына аның улы Архелай патшалык иткәнне ишетеп, анда барырга курыкты. Төшендә Аллаһыдан кисәтү алгач, ул Гәлиләя өлкәсенә юнәлде һәм әүвәле Мәрьям яшәгән Насара шәһәренә килеп урнашты.

Гайсәнең Насарадагы тормышы турында мәгълүмат күп түгел. Аның атасы балта остасы була; аңардан күреп, булышкалап Гайсә дә әлеге һөнәргә өйрәнә. Гайсәнең балалык еллары, үсмер чагы турында Инҗилдә аз язылган. Әмма түбәндәге юллар бик күпне сөйли: «Бала үсә бирде, рухи яктан ныгып, акыл-зиһен җыйды, һәм Аллаһының фатихасы, рәхим-шәфкате Аңа юлдаш булды»; «Үскән саен Гайсәнең гакылы, зирәклеге һаман артып, Аллаһының һәм кешеләрнең мәхәббәтен Ул ныграк яулый барды».

Биредә Гайсәнең ата-ана сүзеннән чыкмавы турында да әйтеп үтәргә кирәк. Бу хакта без Инҗилдә болай дип укыйбыз: «...һәм ата-анасына итагатьле булды». Аллаһы балаларның ата-ананы яратуын һәм алар сүзеннән чыкмавын тели. Аллаһының Ун боерыгының берсе: «Ата-анаңны хөрмәт ит. Шулай эшләсәң, Раббы Аллаң сиңа бирәсе җирдә гомереӊ озын булыр», – дип өйрәтә.

*МАТТАЙ 2:19–23; ЛҮК 2:40, 50–52; ЧЫГЫШ 20:12*



## ЧУМДЫРУЧЫ ЯХЪЯНЫҢ ВӘГАЗЬЛӘВЕ

Рухани Зәкәриянең улы Яхъя чүлдә яшәп көн күрде. Раббы аны үзенә бер төрле, махсус хезмәт өчен әзерли иде. Озакламый Мәсихнең, ягъни Аллаһы сайлаган Затның киләсен хәбәр итеп, Яхъя адәм балаларын тәүбәгә өндәргә тиеш иде. Яхъяның Мәсих килүенә халыкны әзерли торырга тиешлеге турында әле Яхъя туганчы ук йөзәр ел алдан пәйгамбәрләр болай дип язып калдырган була: «Менә, Синең алдыңнан Мин хәбәрчемне җибәрәм, ул барыр юлыңны әзерләр. Чүлдә әнә бер аваз яңгырый: „Раббыга юл әзерләгез, Аның барыр сукмакларын турайтыгыз!“».

Яхъяның өстендә дөя йоныннан хәстәрләнгән кием, билендә күн каеш иде; ашаган ризыгы аның саранча һәм кыр балы булды. Аллаһы Үзенең ихтыярын Яхъяга җиткергәннән соң, Яхъя халыкны вәгазьли башлады. Ул, Үрдүн елгасы буендагы төбәкләрне йөреп чыгып, халыкны тәүбәгә чакырды: «Тәүбәгә килү билгесе итеп суга чуму йоласын башкарыгыз, шул чагында Аллаһы гөнаһларыгызны кичерер», – дип өндәде. Кылган гөнаһларын танып тәүбә итәр өчен, Яхъя янына бөтен Яһүдия җиреннән һәм Иерусалимнан күп халык килә, Яхъя аларны Үрдүн суына чумдырып ала иде.

Халык аңардан: «Нинди гамәлләр кылырга тиеш соң без?» – дип сорагач, ул аларга: «Ике күлмәгең булса, берсен фәкыйрьгә бир; ашар ризыгың булса, ризыгың белән дә бүлеш», – дип җавап кайтара иде. Суга чуму йоласын үтәргә дип салым җыючылар да килделәр һәм Яхъядан: «Остаз! Ә без нинди гамәлләр кылыйк?» – дип сорадылар. Аларга ул: «Халыкны талап бөлдермәгез, тиешеннән артыгын түләтмәгез», – дип җаваплады. Шулай ук гаскәриләр дә аңардан: «Без нишләргә тиеш?» – дип сорадылар. Яхъя: «Берәүне дә рәнҗетмәгез, яла якмагыз һәм хезмәт хакыннан канәгать булыгыз», – диде.

*ИШАГЫЙЯ 40:3; МАЛАХИ 3:1; МАРК 1:1–6; ЛҮК 3:2–14*



## ГАЙСӘ МӘСИХНЕҢ СУГА ЧУМДЫРЫЛУЫ

Халык Мәсихнең килүен көтеп яшәде, шуңа күрә күбесе: «Вәгъдә ителгән Мәсих, Коткаручы шушы Яхъя микән-ни?» – дип бер-берсеннән сораша иде. Әмма Яхъя аларга: «Тәүбәгә килүегезнең билгесе итеп мин сезне суга чумдырам, ләкин минем арттан Килүче күпкә кодрәтлерәк; мин хәтта Аның аяк киемен күтәреп йөрергә дә лаек түгелмен. Менә Ул сезне Аллаһы Рухына һәм утка чумдырыр», – дип җавап бирә иде. Шулай дип аның Гайсә Мәсих турында әйтүе иде.

Шулай беркөнне, Яхъя суга чумдырып алсын өчен, аның янына Гайсә килде. Яхъя Аны туктатмакчы булып: «Син мине чумдырырга тиешсең, ә Син миңа килгәнсең!» – дип әйтеп карады, әмма аңа җавап итеп Гайсә: «Хәзергә шулай булсын, чөнки без Аллаһы кушканны үтәргә тиешбез», – диде. Шуннан Яхъя риза булды. Гайсә, суга чумып ярга чыгуга, күк капусы ачылып китте, һәм Яхъя күгәрчен рәвешендәге Аллаһы Рухының Гайсәгә таба иңүен күрде. Аннары күкләр киңлегеннән: «Бу – Минем сөекле Улым, Ул – Минем куанычым», – дигән өн килеп иреште.

*МАТТАЙ 3:11–17*



## ГАЙСӘ МӘСИХНЕҢ УНИКЕ ШӘКЕРТЕ

Насарадан киткәндә Гайсә инде җиткән егет иде. Ул Гәлиләя өлкәсендәге Геннисарет күле буенда урнашкан Кәпәрнаум шәһәренә килеп төпләнде. Әлеге күлне ул заманнарда Гәлиләя диңгезе дип тә атыйлар иде. Шул рәвешле, Ишагыйя пәйгамбәрнең: «Диңгезгә илтүче юл буендагы Зәбулун җире, Нәптали җире! Үрдүн аръягы! Мәҗүсиләр иле Гәлиләя! Караңгылыкта яшәүче халкың бөек яктылык күрде, үлем караңгылыгында яшәүчеләр өчен нур балкыды», – дип әйткәннәре гамәлгә ашты.

Шул вакытлардан башлап Гайсә: «Тәүбә итегез! Күкләр патшалыгы инде бик якын!» – дип халыкны өндәргә тотынды. Төрле төбәкләрдән җыелган халык Аның артыннан ияреп йөрде, Ул аларга үгет-нәсыйхәт бирде, авыручыларны савыктырды.

Беркөнне Әндри исемле берәү үзенең кардәше Шимун белән (кайвакыт аны Петер дип тә йөртәләр иде) Гәлиләя диңгезендә балык тота иде. Аларны күреп, Гайсә: «Миңа ияregез! Мин сезне кеше аулаучы итәрмен», – диде. Бу сүзләр «кешеләр хакыйкатьне танып белсен өчен, Мин сезне алар янына Яхшы хәбәрне сөйләргә җибәрермен» дигәнне аңлата иде. Әндри белән Петер, ятьмәләрен калдырып, шундук Гайсә артыннан иярделәр. Арырак киткәч, Гайсә көймә эчендә аталары Зебедәй белән бергә ятьмәләрен сипләп утыручы агалы-энеле Ягъкубны һәм Яхъяны күреп алды. Гайсә аларны Үзе белән чакырды, һәм тегеләр, көймәне дә, аталарын да калдырып, Аның артыннан иярделәр. Шулай ук башка шәкертләр дә Гайсә чакыруга шундук Аның артыннан киттеләр. Гайсә аларга авыруларны савыктыру һәм җеннәрне куып чыгару өчен көч бирде.

Шулай итеп, һәрчак Аның янында булсыннар өчен, Гайсә унике шәкерт сайлап алды һәм аларны үзенә бер төрле итеп өйрәтте. Әлеге шәкертләрнең исемнәре түбәндәгечә: Шимун, Әндри, Яхъя, Ягъкуб, Филип, Бартулумай, Маттай, Томас, Һалфай улы Ягъкуб, Таддай, Көрәшүче Шимун һәм Гайсәгә хыянәт итәчәк Яһүд Искариот. Гайсәнең бөтен шәкертләре гап-гади кешеләр иде, әмма Аллаһы Тәгалә аларга Гайсә Мәсихнең, Аллаһы Улының дуслары һәм шәкертләре булу бәхетен бирде.

*МАТТАЙ 4:12–22; МАРК 3:14–19*



## ТАУДА СӨЙЛӘГӘН ВӘГАЗЬДӘН: ЧЫН БӘХЕТ НИГЕЗЛӘРЕ

Бервакыт Гайсә, җыелып торган халык төркемен күреп, тауга күтәрелде. Аның шунда халыкка укылган вәгазе «таудагы вәгазь» дип атала. Муса пәйгамбәр заманында Аллаһы Үз халкына ирештергән Ун канундагы сыман, таудагы вәгазьдә дә кеше яшәешенең әхлакый нигезләре һәм Аллаһы патшалыгына алып баручы туры юл хакында сүз бара. Шәкертләре һәм җыелган кешеләр Гайсә янынарак килеп урнашканнан соң, Ул Үзенең вәгазен башлады:

Рухи яктан фәкыйрь булганнар бәхетле, чөнки Күкләр патшалыгы аларныкы.

Хәсрәте булганнар бәхетле, чөнки алар юаныч табар.

Тыйнак-сабырлар бәхетле, чөнки аларга мирас булып җир калыр.

Раббы ихтыярын үтәргә омтылучылар бәхетле, чөнки аларның теләге үтәлер.

Шәфкатьлеләр бәхетле, чөнки аларга шәфкать күрсәтелер.

Саф күңеллеләр бәхетле, чөнки алар Аллаһыны күрерләр.

Татулык урнаштыручылар бәхетле, чөнки Аллаһы аларны Үзенең балалары дип атар.

Аллаһы ихтыярын үтәү юлында эзәрлекләнүчеләр бәхетле, чөнки Күкләр патшалыгы аларныкы.

Минем аркада сезне хурлаганда, эзәрлекләгәндә һәм сезгә каршы төрле явызлыклар кылынганда, сез бәхетле; шатланыгыз һәм куаныгыз, чөнки күкләрдә әҗерегез зур булыр: сезгә кадәр яшәгән пәйгамбәрләрне дә шулай эзәрлекләделәр.

Сез – җирнең тозы. Әгәр тоз үзенең тәмен югалтса, аңа ничек тәмен кайтарасың?! Кешеләрнең аяк астына чыгарып ташлаудан башка ул бүтән бернигә ярамас.

Сез – дөнья яктысы. Тау башындагы шәһәр кеше күзеннән яшеренеп кала алмас. Шәмгә ут алгач та, аны чүлмәк астына куймыйлар, бәлки шәмдәлгә утырталар, һәм ул өйдәгеләрнең барысына да яктылык бирә. Сезнең яхшы эшләрегезне күреп Күктәге Атагызны данласыннар өчен, сезнең яктылык та кешеләр алдында шулай балкысын.

*МАТТАЙ 5:1–16*



## ТАУДА СӨЙЛӘГӘН ВӘГАЗЬДӘН: МУСА КАНУНЫ ТУРЫНДА

Минем хакта, Муса канунын яки пәйгамбәрләр язганны юкка чыгарырга килгән бу, дип уйламагыз, чөнки Мин юкка чыгарыр өчен түгел, ә бәлки аларны үтәр өчен килдем. Хак дөресен әйтәм сезгә: күк белән җир бар чакта Канунның бер хәрефе дә, бер сызыгы да юкка чыкмас, барысы да тормышка ашар! Димәк ки, кем дә булса, Канунның кечкенә бер таләбен бозып, кешеләрне дә шуңа өйрәтсә, Күкләр патшалыгында ул иң кечесе булыр; Канун таләпләрен төгәл үтәп, кешеләрне дә шуңа өйрәтүче исә Күкләр патшалыгында бөек булыр. Сезгә әйтәм: тәкъвалыгыгыз фарисей* яки Канун белгечләренекеннән өстен булмаса, Күкләр патшалыгына керә алмассыз.

«Үтермә! Кеше җанын кыючы хөкем ителер», — дип ата-бабаларыгызга әйтелгән сүзне ишеткәнегез бардыр. Ә Мин сезгә, үзенең туганына ачу тотучы кеше хөкем ителсен, дип әйтәм; туганына «Яраксыз!» дип әйтүче Югары киңәшмә алдында җавапка тартылсын; ә инде «Ахмак!» дип әйтүче җәһәннәм утына дучар булсын. Димәк ки, әгәр дә син, Аллаһыга дигән бүләгеңне алып килеп, мәзбәх янында туганыңның сиңа булган кинәсен исеңә төшерсәң, бүләгеңне шунда калдырып торып, башта туганың белән татулаш, аннары, килеп, корбан бүләгеңне тапшыр.

«Зина кылма!» — дип ата-бабаларыгызга әйтелгән сүзне ишеткәнегез бардыр. Ә мин сезгә, хатын-кызга җенси теләк белән караучы инде күңеленнән зина кылган санала, дип әйтәм. «Берәр кеше хатынын аерып җибәрсә, аңа аерылышу кәгазе бирсен» дип тә әйтелгән. Ә Мин сезгә, хатыны зина кылмаган очракта ире аның белән аерылыша икән, димәк ул ир үзенең хатынын зина кылуга этәрә, дип әйтәм. Аерылган хатынга өйләнгән кеше дә шулай ук зина кыла.

«Антыңны бозма! Раббы каршында биргән антыңны үтәми калма», — дип ата-бабаларыгызга әйтелгән сүзне дә

* *Фарисей — Яһүдиядәге дини-сәяси оешма әгъзасы. Фарисейлар Муса канунын һәм шуңа өстәлгән башка кагыйдәләрне төгәл үтәүне алга сөргәннәр.*



ишеткәнегез бардыр. Ә Мин сезгә болай дип әйтәм: гомумән ант итмәгез – күк белән дә, чөнки ул Аллаһы тәхете; җир белән дә, чөнки ул Аллаһының аяк асты; Иерусалим белән дә, чөнки ул Бөек Патшаның каласы; башыгыз белән дә, чөнки чәчегезнең бер генә бөртеген дә ак яки кара итә алмыйсыз. Килешәсез икән – «әйе», килешмисез икән – «юк» дигән сүздән башка бүтән җавабыгыз булмасын, чөнки шуннан артыгы – шайтаннандыр.

*МАТТАЙ 5:17–37*

## ТАУДА СӨЙЛӘГӘН ВӘГАЗЬДӘН: МӘХӘББӘТҺӘМ ДОГА ТУРЫНДА

«Күз урынына – күз, теш урынына – теш», – дип борынгыдан килгән сүзләрне ишеткәнегез бардыр. Мин исә сезгә, явыз белән явыз булма, дип әйтәм. Синең бер яңагыңа суккан кешегә икенчесен дә куй. Кем дә булса сине хөкемгә тартып күлмәгеңне алырга теләсә, аңа бишмәтеңне дә салып бир; кемдер сине үзе белән бергә мең адым җир үтәргә мәҗбүр итсә, аның белән ике мең адым үт. Синнән нәрсә дә булса сорасалар – бир, синнән бурычка алырга теләүчене дә буш итмә.
«Якыныңны ярат, дошманыңа нәфрәт белән кара!» – дип борынгыдан килгән сүзләрне ишеткәнегез бардыр. Ә Мин сезгә болай дип әйтәм: дошманыгызны яратыгыз, сезгә ләгънәт укучыларны фатихалагыз, сезгә нәфрәт белән караучыларга яхшылык эшләгез, сезне кыерсытучылар һәм эзәрлекләүчеләр өчен дога кылыгыз. Шул чагында сез Күктәге Атагызның балалары булырсыз, чөнки Үзенең кояшына Ул явызлар өчен дә, рәхимлеләр өчен дә калкырга боера, яңгырын тәкъваларга да, гөнаһлыларга да яудыра. Әгәр сез үзегезне яратучыларны гына яратсагыз, Аллаһы сезгә нәрсә өчен әҗерен бирер?! Салым җыючылар да шулай итә түгелме соң?! Әгәр дусларыгыз белән генә сәламләшсәгез, ул кадәр искитәрлек нәрсә эшләгән булырсыз?! Мәҗүсиләр* дә шулай эшли түгелме соң?! Димәк ки, Күктәге Атагыз камил булган кебек, сез дә шулай камил булыгыз.
Карагыз аны, тәкъва эшләрегезне кешеләр күрсен өчен генә башкармагыз. Ул чагында Күктәге Атагыздан әҗер алмассыз. Шулай ук «күрегез, сәдака бирәм!» дип кычкырып йөрмәгез; икейөзле кешеләр генә гыйбадәтханәдә, урамда макталыр өчен шулай эшлиләр. Хак дөресен әйтәм сезгә: андыйлар кылган гамәлләре өчен әҗерен алды инде. Хәер биргән чакта уң кулың ни кылганны сулы белмәсен, әлеге гамәлең яшертен эшләнсен. Яшертен эшләрнең һәммәсен күреп торучы Атаң сиңа һичшиксез әҗерен бирер.
Гыйбадәтханәләрдә, шулай ук урам чатларында тукталып, башкалар күрсен өчен дога кылган икейөзле бәндәләр сыман булмагыз. Хак дөресен әйтәм сезгә: әҗерен алды инде алар. Син исә, дога кылганда бүлмәңә кереп, ишегеңне яп

---

* *Мәҗүсиләр – пот-сыннарга табынучылар.*

һәм күзгә күренмәс Атаңа дога кыл. Яшертен эшләрнең һәммәсен күреп торучы Атаң сиңа һичшиксез әҗерен бирер. Дога кылганда, «күбрәк сөйләсәк, догабыз кабул булыр» дип уйлаган мәҗүсиләр сыман, артыгын сөйләмәгез. Алар кебек булмагыз, чөнки сез сораганчы ук Атагыз нәрсәгә мохтаҗ булуыгызны алдан ук белеп тора. Сез болай дип дога кылыгыз:

## Күктәге атабыз!

**Исемең изге дип икърар ителсен*,
Синең Патшалыгың килсен; күктәге кебек,
җирдә дә Синең ихтыярың гамәлгә ашсын.
Көндәлек икмәгебезне безгә көн дә биреп
тор. Безгә явызлык кылучыларны без
кичергән кебек, Син дә безнең явыз
эшләребезне кичер. Безне сынауларга
дучар итмә, ә явыздан сакла.**

---

* *Икърар ителсен – әйтелсен, танылсын.*

*МАТТАЙ 5:38 – 6:13*

## ГАЙСӘНЕҢ БИШ МЕҢ КЕШЕНЕ РИЗЫКЛАНДЫРУЫ

Бервакыт Гайсә Үзенең шәкертләре белән Гәлиләя диңгезенең аръягына, Тибериас каласы тарафына юнәлде. Аның артыннан бик күп халык иярде, чөнки алар Гайсәнең, хаста кешеләрне савыктырып, искитәрлек могҗизалар кылуын белә иде.

Гайсә, тау битенә менеп, Үзенең шәкертләре белән сөзәгрәк урынга барып утырды. Яһүдләрнең Котылу бәйрәме якынлашып килгән көннәр иде. Килгән халыкның күплеген күреп, шәкерте Филипкә Гайсә: «Аларны ашатырга кайдан икмәк сатып алырбыз икән?» – диде. Әлеге сүзләрне Ул Филипне сынар өчен генә әйтте, чөнки Үзенең нәрсә эшләргә җыенганын белә иде.

«Ике йөз динарга* икмәк сатып алсак та, һәркайсына берәр телем икмәк тә чыкмаячак», – дип җаваплады Филип.

Гайсә шәкертләренең берсе – Шимун Петернең энесе Әндри: «Монда бер малайның биш арпа икмәге белән ике балыгы бар, әмма моның кадәр халык өчен нәрсә генә ул?!» – диде. «Халыкка утырырга кушыгыз», – дип әйтте Гайсә. Ул урында куе булып чирәм үскән иде, биш мең чамасы ир-ат чирәм өстенә утырышты.

Гайсә, икмәкне алып, шөкрана кылды һәм, халыкка таратыр өчен, шәкертләренә бирде, шулай ук, һәркем теләгән кадәр ашасын өчен, балыкны да бирде. Һәммәсе ашап туйганнан соң, шәкертләренә Ул: «Калган сыныкларны җыеп алыгыз, бернәрсә дә әрәм булмасын», – диде. Кешеләр ашаганнан соң да әле биш арпа икмәгеннән калган сыныклар белән унике кәрзин тулды.

Гайсә кылган әлеге могҗизаны күреп, кешеләр: «Дөньяга килергә тиеш булган Пәйгамбәр чынлап та шушыдыр», – диештеләр.

*ЯХЪЯ 6:3–14*

---

* *Динар – ул заманда Рим империясендә, шул исәптән Исраилдә дә кулланышта йөргән көмеш тәңкә. Эшченең бер көнлек хезмәт хакы.*



## ГАЙСӘНЕҢ КЫЯФӘТЕ ҮЗГӘРҮ

Бервакыт Гайсә, шәкертләре Петерне, Ягъкубны һәм Яхъяны ияртеп, биек тау башына күтәрелде. Дога кылган вакытта кинәт кенә Аның бөтен кыяфәте үзгәреп китте: йөзе кояш сыман балкып, өстендәге киемнәре көн яктысыдай ап-ак булды. Аннары шәкертләре Гайсә белән әңгәмә корып торучы Муса белән Ильяс пәйгамбәрне күрделәр. Шушы хәлгә тәмам исе киткән Петер Гайсәгә: «И Хакимебез! Ничек рәхәт биредә! Әгәр теләсәң, әйдә ботаклардан өч чатыр корыйк: берсе Сиңа, берсе Мусага, берсе Ильяска булыр», – диде. Шул сүзләрне әйтеп бетерүгә, аларны яп-якты болыт чорнап алды да каяндыр болытлар арасыннан бер өн килеп иреште: «Бу – Минем сөекле Улым, Ул – Минем куанычым, Аның сүзеннән чыкмагыз!»

Әлеге тавышны ишетеп, котлары алынган шәкертләр җиргә капландылар. Гайсә, яннарына килеп, аларга орынды да: «Торыгыз, курыкмагыз!» – диде. Күтәрелеп карагач, шәкертләре Гайсәдән башка беркемне күрмәделәр.

Алар белән бергә таудан төшкән чакта Гайсә Үзенең шәкертләренә: «Адәм улы, үлеп, кабат терелгәнчегә кадәр биредә күргәннәрегез турында һичкемгә әйтмәгез», – диде.

*МАТТАЙ 17:1–9; ЛҮК 9:28–36*



## ШӘФКАТЬЛЕ САМАРЕЯЛЕ ХАКЫНДА ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯ

Канун белгечләреннән берәү, Гайсәне сынамакчы булып: «Остаз, мәңгелек тормышка ирешер өчен миңа нишләргә кирәк?» – дип сорау бирде. Гайсә аңа: «Бу хакта Канунда ничек язылган соң?» – диде. Канун белгече: «Анда, Раббы Алланы бөтен күңелең, бөтен җаның, бөтен көчең һәм акылың белән ярат; якыныңны да үзеңне яраткан кебек ярат, дип язылган», – диде. Гайсә аңа: «Җавабың дөрес синең, кылган гамәлләрең шундый булса, яшәрсең», – дип әйтте. Әмма ул адәм, үзен ничектер акламакчы булып, Гайсәдән: «Ә минем якыным кем була соң?» – дип сорады. Аңа җавап итеп, Гайсә бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Бер адәм, Иерусалимнан Әрихә шәһәренә барганда, юлбасарлар кулына эләккән дә, тегеләр, аның киемнәрен талап алып, үзен бик каты кыйнаганнар һәм шунда юл өстендә калдырып киткәннәр. Бер руханига, юлы төшеп, шул яклардан үтәргә туры килгән; әлеге адәмне күргәч, ул, юлның икенче ягына чыгып, ары киткән. Шулай ук левиләрдән, ягъни рухани ярдәмчеләреннән дә берәү, шул турыдан узып барышлый әлеге адәмне якынрак килеп карап, юлын дәвам иткән. Гомер-гомергә яһүдләр белән дошмани мөнәсәбәттә яшәгән самареялеләрдән берәү, юлда яткан адәмне күреп, бик кызганган һәм, аның янына килеп, яраларын шәраб белән юган да зәйтүн мае сөртеп бәйләгән, аннары аны, үзенең ишәгенә атландырып, кунакханәгә алып кайткан, анда да ялалыны игътибарыннан читтә калдырмаган. Икенче көнне исә юлга чыгар алдыннан кунакханә хуҗасына акча калдырып: «Күз-колак булсаң иде аңа, чыгымнарың зуррак булса, кире әйләнеп кайтканда түләрмен», – дигән.

Гыйбрәтле хикәясен сөйләп бетергәннән соң, Канун белгеченнән Гайсә: «Ничек уйлыйсың, әлеге өч кешенең кайсысы юлбасарлар кулына эләккән адәмнең якыны булыр икән?» – дип сорады. «Аңа шәфкать күрсәткәне», – дип җавап бирде теге. Шуннан Гайсә аңа: «Бар, син дә шундый гамәлләр кылып яшә», – диде.

*ЛҮК 10:25–37*



## ЮЛДАН ЯЗГАН ЕГЕТ ТУРЫНДА ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯ

Гайсә тагын бер гыйбрәтле хикәя сөйләде:

Бер кешенең ике улы булган; бервакыт шуларның кечерәк дигәне атасына: «Әти! Милекнең миңа тиешле өлешен бүлеп бир», – дип әйткән. Атасы милекне улларына бүлеп биргән. Ничәдер көн үтүгә, кече улы бар булган акчасын алган да ерак илгә чыгып киткән һәм анда, азгынлыкка бирелеп, байлыгын туздырып бетергән. Ул шулай бөтен мөлкәтен туздырып бетергәннән соң, бу илдә бик каты ачлык башланган, һәм егет тәмам фәкыйрьлеккә төшкән. Чарасыз калып, ул әлеге илнең бер кешесенә эшкә ялланган, һәм теге аны үзенең басуына дуңгыз көтәргә җибәргән. Егет дуңгызлар ашый торган азыкка да шат буласы икән, тик аңа беркем берни бирмәгән. Берзаман ул, исенә килеп: «Атам йортында күпме ялчы туйганчы ашый ала, ә мин биредә ачка интегәм. Хәзер үк атам янына кайтыйм да: „Әти, мин күкләр каршында да, синең каршыда да гөнаһлымын, инде хәзер мин синең улың дип аталырга да лаек түгелмен; ялчыларыңның берсе булырга рөхсәт ит миңа,“ – дип әйтим», – дигән дә атасы янына кайтырга чыккан.

Атасы аны, ерактан ук күреп алып, бик кызганган, каршына йөгереп барып кочаклап үпкән. Улы аңа: «Әти! Мин күкләр каршында да, синең каршыда да гөнаһлымын, инде хәзер мин синең улың дип аталырга да лаек түгелмен», – дигән. Атасы исә үзенең хезмәтчеләренә: «Иң яхшы киемнәр алып килеп киендерегез аны, аягына – сандал, бармагына йөзек кидерегез; шуннан соң симертелгән берәр бозауны алып чыгып чалыгыз – ашап-эчеп күңел ачыйк! Чөнки минем бу улым үлгән иде – инде терелде, югалган иде – табылды», – дип әйткән.

Бу вакытны аның өлкән улы басуда булган. Өенә кайтып җитәрәк, ул җыр-бию тавышлары ишеткән һәм хезмәтчеләрнең берсеннән: «Бу ни хәл?» – дип сораган. Хезмәтче аңа: «Энең исән-сау әйләнеп кайткан хөрмәткә әтиең симертелгән бозау чалды», – дигән. Өлкән улының бу хәлгә ачуы чыгып, ул хәтта өйгә дә керергә теләмәгән. Атасы исә, аның янына чыгып, өйгә керүен үтенгән. Ләкин ул: «Мин инде ничә еллар сиңа хезмәт итәм, кушканнарыңны һич карусыз башкарам;



шуңа карамастан, дусларым белән күңел ачар өчен, синең миңа кәҗә бәтие дә биргәнең юк. Ә инде милкеңне фахишәләр белән туздырып бетергән улың кайткач, аның өчен син симертелгән бозау чалгансың», — дип үзенең үпкәсен белдергән.

Аңа җавап итеп атасы: «Улым! Син һәрвакыт минем янда, минем бар мөлкәтем — синеке. Синең энең үлгән иде — хәзер ул терелде, югалган иде — табылды, әнә шуңа шатланырга һәм күңел ачарга кирәк», — дигән.

*ЛҮК 15:11–32*

## «БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ИҢ МӨҺИМ БОЕРЫК»

Бервакыт Канун белгечләреннән берсе, Гайсә янына килеп: «Остаз! Канундагы боерыкларның иң мөһиме кайсы?» – дип сорады. Аңа җавап итеп Гайсә: «Раббы Алланны бөтен күңелең, бөтен җаның, бөтен акылың белән ярат, – диде. – Бу иң беренче һәм иң мөһим боерык. Икенчесе дә нәкъ шундый: якыныңны үзеңне яраткан кебек ярат. Муса пәйгамбәр аша бирелгән Канун да, пәйгамбәрләрнең китаплары да шушы ике боерыкка нигезләнә».

*МАТТАЙ 22:36–40*



## ГАЙСӘНЕҢ ШӘКЕРТЛӘР БЕЛӘН УЗДЫРГАН СОҢГЫ МӘҖЛЕСЕ

Котылу бәйрәме җиткәч, Гайсә: «Барыгыз, Котылу бәйрәме хөрмәтенә безгә табын әзерләгез», – дип Петер белән Яхъяны Иерусалимга җибәрде. Тегеләр исә Аңардан: «Кайда әзерләргә кушасың?» – дип сорагач, Гайсә: «Шәһәргә аяк басуга, сулы чүлмәк күтәреп барган бер адәмне очратырсыз. Аның артыннан ияреп, ул кергән йортка керегез һәм хуҗа кешегә: „Остазыбыз синнән, Котылу бәйрәменә багышланган ашны Мин Үземнең шәкертләрем белән кайсы бүлмәдә ашый алырмын икән, дип сорый“, – диегез. Ул сезгә җыештырып куелган зур бүлмәне күрсәтер – шунда әзерләгез», – диде. Шәкертләре китеп бардылар, һәм барысы да Гайсә әйткәнчә булып чыкты; шуннан алар табын әзерләделәр.

Вакыты җиткәч, Гайсә һәм Аның унике шәкерте ашарга утырдылар. «Газапка дучар ителгәнче, Котылу бәйрәме табынында сезнең белән утырып ашарга шундый теләгән идем! – диде Гайсә. – Котылу бәйрәме хөрмәтенә әзерләнгән ризыктан авыз итәр көн Аллаһы патшалыгында җитми торып, Мин инде аны бүтән ашамаячакмын». Аннары, кулына касәне алып, шөкрана кылды да әйтте: «Кабул итеп алыгыз да үзара бүлешегез. Әйтәм бит, Аллаһы патшалыгы җитмичә, Мин инде йөзем шәрабы эчмәячәкмен».

Шуннан Гайсә кулына икмәк алды, шөкрана кылып, шәкертләренә сындырып бирде дә: «Бу – сезнең хакка бирелә торган тәнемдер. Икмәкне сындырып ашап, Мине шулай искә алырсыз», – диде. Аштан соң, касәне алып, шулай ук шәкертләренә сузды һәм: «Бу – сезнең хакка түгелә торган канымдыр. Аллаһы шушы кан белән Үзенең Яңа килешүен беркетә», – диде.

*ЛҮК 22:8–20*



## ГЕТСИМӘНИ БАКЧАСЫНДА КЫЛЫНГАН ДОГА

Шул ук төнне, ашап-эчкәннән соң, Гайсә Үзенең унбер шәкерте белән Иерусалимнан чыгып Гетсимәни дип аталган урынга килде. Шәкертләре белән шундагы бер бакчага кергәч, Гайсә аларга: «Сез биредә калыгыз, Мин читкәрәк китеп дога кылыйм», – диде дә, Үзе белән Петер, Ягъкуб һәм Яхъяны ияртеп, арырак атлады. Күңелен тирән сагыш, җан сызлавы басып алган Гайсә аларга әйтте: «Күңелемдә әҗәлгә тиң зур хәсрәттер, Минем янда йокламыйча төн уздырсагыз иде».

Аннары бераз читкәрәк китте дә җиргә тезләнеп дога кылырга тотынды: «И-и Атам! Әгәр мөмкин булса, бу газаплар касәсе мине читләтеп үтсә иде! Хәер, Мин теләгәнчә түгел, Син ничек ихтыяр кылсаң, шулай булсын!» Шунда Аның янына күктән бер фәрештә иңеп Аңа ныклык бирде. Җаны тулы газап булганга, Гайсә аеруча тырышып дога кылды; җиргә тамган кан тамчылары кебек Аңардан тир акты.

Шәкертләре янына әйләнеп килгәндә, алар йоклый иде. Гайсә, аларны уятып: «Минем янда бер сәгать тә йокламыйча түзә алмадыгыз. Сынауларга бирешмәс өчен, уяу булыгыз һәм дога кылыгыз: рух көчле, тән исә – көчсездер», – диде.

Шәкертләреннән читкә китеп, Гайсә яңадан дога кылды: «И-и Атам! Әгәр бу газаплар касәсе Мине читләтеп үтә алмый һәм Мин аны эчәргә тиеш икән, Син ихтыяр кылганча булсын». Без кылган гөнаһлар өчен Гайсә кичерәсе газаплар турында сүз алып баруы иде Аның.

*МАТТАЙ 26:36–44; ЛУК 22:39–46*



## ГАЙСӘНЕҢ САК АСТЫНА АЛЫНУЫ

Шәкертләре янына Гайсә өч тапкыр әйләнеп килде; Ул кайчан гына килсә дә, алар һаман йокыда булдылар. Өченче тапкыр килүендә Ул: «Әле һаман йоклыйсызмы? Вакыты җитте – Адәм улын әнә гөнаһлылар кулына тапшыралар. Торыгыз, киттек – Миңа хыянәт итүче якын инде», – диде.

Шушы сүзләрне әйтеп тә бетермәде, Гайсәнең унике шәкерттеннән берсе – утыз көмеш тәңкә бәрабәренә Аны баш руханиларга тотып бирергә ризалашкан Яһүд Искариот килеп чыкты. Яһүд белән бергә күп санлы гаскәриләр һәм, кулларына янып торган чыраглар, кылычлар, күсәкләр тотып, фарисейлар вә баш руханилар җибәргән кешеләр дә килгән иде. «Мин кемне үпсәм, шул Гайсә булыр; Аны кулга алырсыз», – дип, хыянәтче Яһүд алар белән сүз куешкан була. Яһүд шунда Гайсә янына килде дә: «Исәнме, Остаз!» – дип Аны үбеп алды. Гайсә исә аңа: «Дус кеше, нәрсәгә дип килдең син? Шул рәвешле, үбеп, Адәм улына хыянәт итәсеңме? – диде, аннары Яһүд белән килгән гаскәриләргә мөрәҗәгать итеп: – Кемне эзлисез сез?» – дип сорады. «Насаралы Гайсәне», – дип җавап бирде тегеләр. «Мин ул», – диде Гайсә. Әлеге сүзләрне ишетүгә, барысы да арткарак чигенеп җиргә капланды. «Юлбасар тотарга чыккан сыман кылычлар, күсәкләр күтәреп Мине алырга килгәнсез, – диде Гайсә. – Мин көн дә, Аллаһы йортында үгет-нәсыйхәт биреп, яныгызда булдым, һәм сез миңа каршы чыгарга базмадыгыз. Әмма хәзер сезнең заман, караңгылык хөкем сөргән вакыт җитте».

Гаскәриләр, Гайсәне сак астына алып, баш рухани йортына таба юнәлделәр, шәкертләре исә, Аны ташлап, кайсы кая качышып беттеләр.

*МАТТАЙ 26:45–49, 56-57; ЛУК 22:45–54; ЯХЪЯ 18:1–12*



## ГАЙСӘ РИМ ИДАРӘЧЕСЕ ПИЛАТ ЯНЫНДА

Таң атуга, барлык баш руханилар һәм шәһәрнең өлкәннәре Гайсәне үлемгә хөкем итәргә дип җыелдылар. Алар Гайсәне бәйләделәр дә Яһүдиядәге Рим идарәчесе Понтий Пилат янына алып килделәр. Гайсәгә хыянәт иткән Яһүд, Гайсәне үлемгә хөкем итүләрен белгәннән соң, тәүбәгә килеп: «Гөнаһ эш кылдым мин, гаепсезгә яла яктым», – дип утыз көмеш тәңкәне баш руханиларга һәм шәһәрнең өлкәннәренә кире кайтарды. Көмеш тәңкәләрне ул Аллаһы йортында атып бәрде дә, чыгып китеп, асылынды.

Гайсәне алып килгән яһүдләр, мәҗүси Пилатның сараена кереп нәҗесләнербез дип, анда аяк басмадылар. Пилат, алар каршына үзе чыгып: «Әлеге кешене сез нәрсәдә гаеплисез?» – дип сорады. Аңа җавап итеп тегеләр: «Әгәр ул явыз җан булмаса, без Аны синең каршыңа алып килмәс идек, – диде. Аннары: – Без Аны халык арасында моткы таратучы дип саныйбыз. Ул Үзен Мәсих, Патша дип атый һәм Рим патшасына салым түләүдән тыя», – дип Гайсәне гаепләргә тотындылар.

Шуннан Пилат сарайга керде һәм, Гайсәне чакыртып алып: «Син яһүдләр патшасымы?» – дип сорады. «Минем Патшалыгым бу дөньяныкы түгел, – дип җавап кайтарды аңа Гайсә. – Әгәр Патшалыгым бу дөньяныкы булса, хезмәтчеләрем Минем өчен көрәшер иде». Пилат: «Димәк ки, Син – патша?» – диде. «Мин хакыйкать турында шаһитлык бирер өчен тудым һәм шуның өчен дөньяга килдем. Хакыйкать яклы булган һәр кеше Минем тавышыма колак сала», – дип җавап бирде Гайсә. «Нәрсә соң ул хакыйкать?» – диде Пилат.

Гайсәнең Һируд патша идарә иткән Гәлиләядән икәнен белгәннән соң, Пилат Аны Һируд янына җибәрде. Ул көннәрдә Һируд Иерусалимда иде. Һируд патша Гайсәгә шактый күп сораулар бирсә дә, Ул аларның берсенә-бер җавап кайтармады. Баш руханилар һәм Канун белгечләре исә, Гайсәне гаепләп, яла өстенә яла өйделәр. Ләкин Һируд, үзенең гаскәриләре белән бергә Гайсәне кимсетеп, мәсхәрәләп, Аңа патша киемнәре кигертте дә кабат Пилат янына озатты. Моңарчы берсен-берсе дошман күргән Пилат белән Һируд шул көннән дуслашып киттеләр.

Пилат, яһүдләрнең баш руханиларын, түрәләрен һәм халыкны җыеп, аларга: «Әлеге кешене сез минем янга „халык арасында моткы тарата“ дип алып килдегез. Мин сезнең алда Аңардан



сорау алдым, тик сез таккан гаепләрнең берсен дә хаклы дип тапмадым», – диде. Кабул ителгән гадәт буенча, Пилат бәйрәм хөрмәтенә бер тоткынны азат итәргә ниятли һәм нәкъ менә Гайсәне ирекkә җибәрергә җыена иде. Әмма бар халык бертавыштан: «Үлем Аңа! Безгә Барабны азат ит!» – дип кычкырырга тотынды. Әлеге Бараб, шәһәрдә чуалышлар оештыруда һәм кеше үтерүдә гаепләнеп, төрмәдә утыручы бер бәндә иде. Пилат, Гайсәне азат итәргә омтылып, тагын халыкка мөрәҗәгать итеп карады, әмма халык: «Хачка кадакла Аны, хачка!» – дип таләп итүендә булды; һәм аларның кычкыруы Пилатның тавышыннан көчлерәк булып чыкты.

*МАТТАЙ 27:1–4; ЛУК 23:2, 7–23; ЯХЪЯ 18:28–30, 33–38*

## «ҮЗЕНЕҢ ХАЧЫН КҮТӘРЕП...»

Шуннан соң Пилат, Гайсәне сак астына алып, камчы белән суктырырга кушты. Гаскәриләр Аның башына күгән ботакларыннан үрелгән таҗ, өстенә куе кызыл төстәге япанча кидерделәр дә: «Яшәсен яһүдләр патшасы!» – дип йөзенә суктылар. Пилат, янә халык янына чыгып: «Мин Аны хәзер сезнең янга чыгарам, ләкин белеп торыгыз, мин Аның бер генә гаеп эшен дә күрмим», – дип әйтте.

Шулвакыт башына чәнечкеле таҗ, өстенә куе кызыл төстәге япанча кигән Гайсә килеп чыкты. «Менә ул Кеше!» – диде Пилат. Гайсәне күреп алуга, баш руханилар һәм сакчылар: «Хачка кадакла Аны, хачка!» – дип кычкырырга тотындылар. «Мин Аның бернинди гаеп эшен күрмим!» – дип кабатлады Пилат. «Безнең Канун буенча Ул үләргә тиеш, чөнки Үзен Аллаһы Улы дип атады», – дип җавап кайтарды яһүдләр. Әлеге сүзләрне ишетеп, Пилат тагын да ныграк курка калды һәм, яңадан сарайга кереп, Гайсәдән: «Кайдан килдең Син?» – дип сорады. Әмма Гайсә дәшмәде. «Миңа җавап бирәсең килмиме? Сине хачка кадаклатырга яисә азат итәргә хокукым барлыгын белмисеңме әллә?» – диде Аңа Пилат. «Әгәр сиңа югарыдан бирелмәсә, Минем өстән һичнинди хокукың булмас иде. Шуңа күрә синең кулга Мине тотып биргән кешенең гөнаһы зуррак», – дип җавап кайтарды Гайсә. Шушы сүзләрне ишеткәннән соң, Пилат Аны азат итү юлларын эзли башлады.

Ул, Гайсәне сарайдан алып чыгып, үзе хөкемче урындыгына килеп утырды. «Менә сезнең патшагыз!» – диде Пилат яһүдләргә. Ләкин алар: «Олактыр Аны, хачка кадакла!» – дип кычкырырга тотынды. «Мәсих дип аталган Гайсә белән нишләргә соң?» – диде Пилат. «Хачка кадакларга Аны!» – дип кычкырды бөтенесе бер булып. «Нинди явызлык кылды соң Ул?» – дип сорады идарәче. Ләкин халык: «Хачка кадакларга Аны!» – дип тагын да ныграк кычкыруында булды. Пилат, бөтен тырышлыгының нәтиҗәсез булуын, шулай ук халык арасында ыгы-зыгы артуын күреп, халык алдында кулларын суда чайкап алды да: «Бу Адәмнең үлемендә минем гаебем юк. Җавабын үзегез бирәсе», – диде. Аның сүзләренә каршы халык: «Гаебе безгә һәм безнең балаларга төшсен!» – дип



кычкырды. Шуннан Пилат аларга Барабны азат итте, Гайсәне исә, камчы белән суктырып, хачка кадакларга боерды.

Гаскәриләр Гайсәне җәза буласы урынга алып киттеләр. Гайсә, Үзенең хачын Үзе күтәреп, яһүдчә Гөлгетә дип аталган җәза мәйданына юнәлде. Аның артыннан бик күп халык ияреп барды, алар арасында Гайсәне кызганып үкси-үкси елаган хатын-кыз да байтак иде. Гайсә, аларга таба борылып: «Минем хакта күз яшьләре түкмәгез, Иерусалим кызлары! – диде. – Үзегезне һәм балаларыгызны кызганып яшь түгегез, чөнки „кысыр хатыннар, әле бала тудырмаган һәм күкрәк сөте имезмәгән хатыннар бәхетле икән“ дип әйтер көннәрегез якынлаша».


*МАТТАЙ 27:20–26; ЛУК 23:27–29; ЯХЪЯ 19:1–17*

## ГАЙСӘНЕ ХАЧКА КАДАКЛАУ

Гайсә белән бергә шулай ук үлемгә хөкем ителгән тагын ике җинаятьчене алып бардылар. Җәза мәйданына килеп җиткәч, аларның өчесен дә хачка кадакладылар, теге явыз җаннарның берсен – Гайсәнең уң ягына, икенчесен – сул ягына. «Йа Атам! Гафу кыл бу кешеләрне, чөнки нәрсә эшләгәннәрен белмиләр», – диде Гайсә. Пилат кушканча, язу язып хачка беркеттеләр. Анда яһүд, грек һәм латин телендә: «Насаралы Гайсә, яһүдләр Патшасы», – дип язылган иде.

Гайсәне хачка кадаклагач, гаскәриләр Аның киемнәрен үзара бүлештеләр, япанчасына исә жирәбә салдылар. Халык моны күреп-карап торды. «Башкаларны коткарды бит, әгәр Аллаһы тарафыннан сайланган Мәсих икән, Үзен коткарсын», – дип, башлыклар Гайсәне мыскыллап көлде. Шулай ук гаскәриләр дә, Аңа әче шәраб тәкъдим итеп һәм: «Әгәр Син яһүдләр патшасы булсаң, Үз-үзеңне коткар», – дип, мәсхәрәләп көлделәр. Хачка кадакланган җинаятьчеләрнең дә берсе, явыз телләнеп: «Алай Мәсих булгач, Үзеңне дә, безне дә коткар», – диде. Икенче җинаятьче исә, тегене тыеп: «Син үзең дә Аның кебек үк хөкем ителгән бит, әллә бер дә Аллаһыдан курыкмыйсыңмы? Синең белән мине гадел хөкем иттеләр, кылган гамәлләребезгә карата тиешлесен алдык, ә Ул бер яманлык та эшләмәде, – диде, аннары Гайсәгә мөрәҗәгать итеп: – Үзеңнең Патшалыгыңа килгәч, мине искә ал, Гайсә!» – диде. «Хак дөресен әйтәм сиңа: бүген үк Минем белән бергә җәннәттә булырсың», – дип җавап бирде Гайсә. Көн урталары җиткән иде инде. Шулвакыт, кояш сүнеп, бөтен җир йөзен караңгылык басып алды, һәм шушы хәл көндезге өчләргә кадәр дәвам итте. Шунда Гайсә җан ачысы белән: «И-и Аллам, Аллам, нигә ташладың Син мине?» – дип кычкырып җибәрде. Янәшәдә басып торган гаскәриләрнең берсе, шундук йөгереп килеп, губка кисәген әче шәрабка манды да, таякка элеп, Гайсәгә эчәргә бирде. Шәрабны татыгач, Ул: «Гамәлгә ашты! – диде, аннары көчле тавыш белән: – Атам! Рухымны Синең кулга тапшырам!» – дип кычкырды да җан бирде.

Шул мизгелдә Аллаһы йортындагы пәрдә өстән аска кадәр урталай ертылып төште, җирләр тетрәп, таш кыялар ярылды, каберләр ачылып китеп, мәрхүм изгеләрнең күбесе терелде һәм



каберләреннән кубарылып чыкты. Ә бераз соңрак, Гайсә үледән терелгәннән соң, әлеге изгеләр Иерусалимга килделәр, һәм күпләр аларны күрде. Йөзбашы һәм Гайсәне саклаучы гаскәриләр, җир тетрәүне һәм шундагы хәлләрне күреп, куркуга калдылар: «Дөрестән дә Аллаһы Улы булган икән», – диеште алар. Җәза мәйданына җыелган бар халык әлеге хәлләрне күргәннән соң кайгыдан күкрәкләрен төя-төя өйләренә таралышты.

*МАТТАЙ 27:45–49, 51–54; ЛУК 23:32–43, 46–48; ЯХЪЯ 19:19–24, 30*

## ГАЙСӘНЕ КАБЕРГӘ САЛУ

Гайсә җомга көнне җан бирде; яһүдләр гәүдәләрне шимбә көнгә хачта калдырырга теләмәделәр, чөнки ул шимбә бөек бәйрәм көне иде. Шуңа күрә алар, гәүдәләрне хачтан төшерергә рөхсәт сорап, Пилат янына керделәр. Идарәченең рөхсәтен алганнан соң, гаскәриләр килделәр дә, тизрәк үлсеннәр өчен, теге ике юлбасарның балтыр сөякләрен сындырдылар; Гайсәнең инде үле булуын күреп, аякларын сындырмадылар. Әмма гаскәриләрнең берсе Аның кабыргасына сөңге белән чәнчеде, һәм ярадан кан белән сүл саркып чыкты. Боларның һәммәсе яһүдләрнең Изге язмаларында әйтелгәнчә булды: «Аның һичбер сөяге сынмас» (Чыгыш 12:46) һәм «Алар үзләре чәнечкән Затка карарлар» (Зәкәрия 12:10) диелгән иде анда.

Шуннан соң Пилат янына Югары киңәшмә әгъзасы, күренекле һәм бай кеше, ариматайлы Йосыф килде. Яһүдләрдән курыкканга күрә, Гайсәнең шәкерте булуын ул яшереп йөрде. Әлеге Йосыф идарәче Пилаттан Гайсәнең гәүдәсен хачтан төшерергә рөхсәт сорады, һәм Пилат аңа ризалык бирде.

Югары киңәшмә әгъзаларының берсе – бервакыт төнлә яшертен генә Гайсә белән очрашкан Никәдим исемле кеше үзе белән зур-зур савытларда хуш исле сумала-майлар алып килгән иде. Яһүдләрнең күмү йоласы буенча алар Гайсәнең гәүдәсен хуш исле майлар сеңдерелгән кәфенгә урадылар. Гайсә хачка кадаклanган урыннан якында гына бер бакча булып, анда кыяны чокып ясалган, әле һичкемнең мәете салынмаган кабер-мәгарә бар иде. Йосыф белән Никәдим, Гайсәнең гәүдәсен шунда урнаштырып, мәгарә авызын зур бер таш белән томалап куйдылар.

Шимбә көнне баш руханилар белән Канун белгечләре, идарәче Пилат янына килеп, Гайсә хакында болай дип әйттеләр: «Әфәнде! Теге ялганчының сүзләре искә төште, Ул бит: „Өч көннән Мин үледән тереләчәкмен“, – дип әйткән иде. Шулай булгач, өч көн дәвамында каберне сакларга әмер бир, югыйсә төнлә шәкертләре, килеп, Аның гәүдәсен урлап китәрләр дә соңыннан халыкка: „Ул үледән терелде“, – дип сөйләп йөрерләр; һәм бу соңгы ялган беренчесеннән яманрак булыр».

Рөхсәт алганнан соң алар, кабер янына сакчылар куеп, мәгарә авызын томалаган ташка мөһер сугып калдырдылар.

*МАТТАЙ 27:57–66; ЯХЪЯ 19:31–42*



## ГАЙСӘНЕҢ ҮЛЕДӘН ТЕРЕЛҮЕ

Шимбә үтеп, икенче көннең таңында бик каты итеп җир тетрәде, чөнки күктән Раббы фәрештәсе төште һәм кабер авызын томалап торган ташны читкә алып ташлады. Фәрештәнең кыяфәте яшенгә тиң, ә киемнәре кардай ап-ак иде. Мәгарә янына сакка куелган гаскәриләр, котлары алынып, тораташтай катып калдылар. Һушларына килгәннән соң, алар шәһәргә юнәлделәр һәм күргәннәре турында баш руханиларга сөйләп бирделәр. Баш руханилар, шәһәрнең өлкәннәре белән җыелышып киңәшләшкәч, гаскәриләргә күп итеп акча бирделәр һәм аларга: «Без йоклаган вакытта төнлә Гайсәнең шәкертләре, килеп, Аның гәүдәсен урлап киткәннәр, – дип әйтергә куштылар. – Әлеге вакыйга турындагы хәбәр идарәчегә барып җитә калса, без аны сезнең гаепсез булуыгызга күндерә алырбыз», – диделәр. Гаскәриләр, акчаны алып, баш руханилар ничек кушкан булса, шулай эшләделәр.

Шул ук көнне магдалалы Мәрьям, Ягъкуб һәм Йосиснең анасы Мәрьям, аннары Салуми исемле бер хатын, иртә таңнан торып, Гайсәнең гәүдәсенә хуш исле майлар сөртергә дип, бакча эчендәге кабер янына киттеләр. «Мәгарә авызындагы ташны аудырырга кем булышыр икән?» – диеште алар бер-берсенә. Килеп җитсәләр – әлеге хәйран зур таш читтә ята. Мәгарә эченә керүгә, алар, ап-ак киемле фәрештәне күреп алып, курка калдылар. «Курыкмагыз! – диде аларга фәрештә. – Хачка кадакланган Гайсәне эзләвегездер. Биредә юк Ул, алдан ук сезгә Үзе әйтеп куйганча, Гайсә үледән терелде. Менә Ул яткан урын. Ә сез хәзер тизрәк Аның шәкертләренә барып хәбәр итегез: Гайсә үледән терелде, Үзенең шәкертләрен Ул Гәлиләядә көтеп тора».

Мәгарәдән чыккач хатыннар, курку катыш шатлык хисләре кичергән хәлдә Гайсәнең үледән терелүе турында хәбәр итәргә дип, Аның шәкертләре янына йөгерделәр.

*МАТТАЙ 28:1–8, 11–15; МАРК 16:1–7, 9*



## ГАЙСӘНЕҢ КҮККӘ АШУЫ

Үледән терелгән Гайсә, әле яңадан кырык көн дәвамында Үзенең шәкертләренә күренеп, аларга Аллаһы патшалыгы турында сөйләде. Ахырда, шәкертләрнең барысын җыеп, Гайсә мондый боерык бирде:

> Иерусалимны ташлап китмәгез, Күктәге Ата вәгъдә иткән бүләкне көтегез. Мин сезгә ул хакта сөйләгән идем. Яхъя суга чумдыра торган иде, сез исә берничә көннән Изге Рухка чумарсыз.
>
> Сезгә Изге Рух иңгәннән соң, көч-кодрәт иясе булырсыз һәм Иерусалим җирендә, шулай ук бөтен Яһүдия, Самарея төбәкләрендә, хәтта дөньяның читендә дә Минем турыда шаһитлык итәрсез.

Шушы сүзләрдән соң Гайсә Мәсих аларның күз алдында күккә аша башлады һәм болытлар арасында күздән юк булды. Алар шулай Гайсәнең күккә ашуын карап югарыга төбәлеп торган чакта кинәт кенә яннарында ап-актан киенгән ике ир-ат пәйда булып: «Гәлиләя ирләре! Нәрсә дип сез күккә текәлеп торасыз? Яныгызда басып торган Гайсә сезнең күз алдында ничек итеп күккә ашкан булса, килгәндә дә нәкъ шул рәвешле киләчәк», – диде.

*РӘСҮЛЛӘРНЕҢ ЭШЛӘРЕ 1:3–5, 8-11*

